# “Галимҗан Гыйльманов әсәрләрендә сәнгати вакыт төшенчәсе бирелеше”

**Автор: Мәүлина Ләйсән Рафаил кызы**
**туган тел һәм әдәбият укытучысы**
**Казан шәһәре Мәскәү районының**
**“Аерым предметлар тирәнтен өйрәнелә**
**торган 55 нче урта гомуми белем**
**мәктәбе” ГББМУ**

# ЭЧТӘЛЕК

Кереш......................................................................................................3

**Беренче бүлек. Тел белемендә сәнгати текстны өйрәнү юнәлешләре**

1.1. Сәнгати текст өйрәнү үзенчәлекләре..................................................8

1.2. Сәнгати вакытны өйрәнү үзенчәлекләре...........................................10

**Икенче бүлек. Г.Гыйльманов иҗатында сәнгати вакыт төшенчәсенең лингвистик чаралар белән бирелеше**

2.1. Вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр................................................18

2.1.1. “Албастылар” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр.......................................................................18

2.1.2. “Оча торган кешеләр” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр...................................................26

2.2.Вакыт төшенчәсен белдергән морфологик чаралар.........................34

2.2.1. “Албастылар” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән морфологик чаралар.........................................................................34

2.2.2. “Оча торган кешеләр” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән морфологик чаралар.....................................................37

2.3. Вакыт төшенчәсен белдерүгә ярдәм иткән график чаралар............41

2.3.1. “Албастылар” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдерүгә ярдәм иткән график чаралар........................................................41

2.3.2. “Оча торган кешеләр” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдерүгә ярдәм иткән график чаралар.........................................44

Йомгак....................................................................................................48

Кулланган әдәбият..................................................................................51

## КЕРЕШ

XX гасырның 80 нче елларыннан башлап татар әдәбиятында реализм яки романтизм кысаларына сыеша алмаган, үзенчәлекле һәм үзгә әсәрләр пәйда булды. Ф.Бәйрәмова, З.Хәким, Н.Гыйматдинова, Р.Зәйдулла һ.б. авторларның аерым әсәрләрен күздә тотып, шушы чорда татарларда да постмодернизм күренешенең мәйданга килүен билгели алабыз.[1]

Шушы авторлар арасында Галимҗан Гыйльманов исеме дә бар. Галимҗан Гыйльмановның иҗаты татар милли сүз сәнгатендә яңа күренеш буларак кабул ителде. Д.Ф.Заһидуллина билгеләвенчә, аның “Албастылар” романы – татар постмодернизм әдәбиятындагы беренче дулкынның югары ноктасы, аның үзгәреш юлын һәм поэтик үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм итүче берәмлек.[2]

Язучының әсәрләре хыял белән реаль дөнья чикләрендә иҗат ителә. Аларда фантастик вакыйгалар белән чынбарлыктагы күренешләрнең югары дәрәҗәдәге синтезы күзәтелә. Г.Гыйльманов үзе әйтүенчә, бу әсәрләр барыбер реалистик рухта булып кала бирә, чөнки алар тормыш логикасына буйсыналар.[3] Язучының әнә шундый кызыклы һәм үзенчәлекле иҗаты әле үз тикшерүчесен көтә.

XX гасыр азагы-XXI гасыр башы галимнәрен һәм әдәбиятчыларын кызыксындырган темаларның берсе әдәби әсәрләрнең текст буларак корылышы мәсьәләләре. Әлеге тема белән кызыксынучы галимнәргә без

---

1 Заһидуллина Д.Ф. “Албастылар” яки татар прозасында яңа сыйфатлар / Д.Ф.Заһидуллина // Казан утлары. – 2001. - № 11. – Б. 111.

2 Шунда ук. – Б. 111.

3 Г.Гыйльманов: “Тормыш кешене үзгәртә”... // Тәрәзә. – 2007. - №1-2. – Б. 12.

Л.А Новиков[4], Л.Г.Бабенко[5], кебекләрне кертә алабыз. Татар галимнәре арасыннан бу өлкәдә В.Х.Хаков[6], Х.Р.Курбатов[7], С.Ш.Поварисов[8], Д.Ф.Заһидуллина[9] эшли. Алар үзләренең фәнни иҗатларында әдәби текстның төзелеш үзенчәлекләрен, тел берәмлекләрен сәнгатьчә куллану мәсьәләләрен һ.б. өйрәнәләр. Текстка филологик анализ ясау анда сәнгати вакыт бирелешен ачыклауны да күз алдында тота. Бу яктан Г.Гыйльманов иҗаты да кызыклы. Ул үз әсәрләрендә вакытның катлаулы формаларын тәкъдим итә, төрле чараларны шушы максаттан куллана. Аның иҗаты бу ноктадан әле тирәнтен өйрәнелмәгән. Бу безнең эшебезнең **актуальлеген** дәлилли.

Әлбәттә, Галимҗан Гыйльманов иҗатына багышланган берничә мәкалә вакытлы матбугатта дөнья күрде. Шулар арасында Д.Ф.Заһидуллинаның “Албастылар” яки татар прозасында яңа сыйфатлар” мәкаләсе[10] үзенең фәнни тирәнлеге белән аерылып тора. Галимә биредә Галимҗан Гыйльмановның әлеге әсәрен постмодернизм үзенчәлекләренең чагылышы ноктасыннан тикшерә. Шулай максатчан анализлау мифологик фикерләүгә корылган кайбер сыйфатларны аерып чыгарырга мөмкинлек бирә.

---

4 Новиков Л.А. Лингвистическое толкование художественного текста / Л.А.Новиков. – М., 1979; Новиков Л.А. Художественный текст и его анализ / Л.А.Новиков. – М., 2007.

5 Бабенко Л.Г. Филологический анализ текста: основы теории, принципы и аспекты анализ / Л.Г.Бабенко. – М, Екатеринбург, 2004; Бабенко Л. Г. Лингвистический анализ художественного произведения. Теория и практика / Л.Г.Бабенко, Ю.В.Казарин. – М.: Флинта, Наука. – 2004.

6 Хаков В.Х. Татар әдәби теле (Стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.

7 Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.

8 Поварисов С.Ш. Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү / С.Ш.Поварисов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978.

9 Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004.

10 Заһидуллина Д.Ф. “Албастылар” яки татар прозасында яңа сыйфатлар / Д.Ф.Заһидуллина // Казан утлары. – 2001. - №11. – Б. 111-119.

Й.Г.Нигъмәтуллина исә язучының бу романын татар әдәбиятында “соңарган” модернизмның бер үрнәге буларак тикшерә.[11]

Әлеге фикерләргә капма-каршы булган карашлар С.Хафизов тарафыннан әйтелә. Ул, Г.Гыйльманов иҗатыннан соңгы елларда гаять популяр булган “изм”нар эзләүне хупламый һәм әсәрләрдә чагылган үзенчәлекләрне татар милли әдәбиятының үз тамырларыннан эзләргә кирәклекне әйтә.[12]

М.И.Ибраһимов да үз тикшерүләрендә “Албастылар” әсәрен мифологизм ноктасыннан өйрәнүгә игътибар бирә, кайбер мифологик мотивларны аерып чыгара. Ул авторның аларны куллану максатын әсәренә мистиклык өстәргә, укучы өчен кызыклы итәргә теләвендә күрә.[13]

Г.Гыйльманов иҗатына игътибар иткән галимнәрдән без яшь галимә Л.Дәүләтшинаның “Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI веков” исемле монографиясенә аеруча тукталырга кирәк дип исәплибез. Ул тикшерү объектларының берсе буларак Г.Гыйльманов әсәрләрен сайлый һәм аларда мифологизм чагылышын билгели.

Язучы  Алмаз Гыймадиев Г.Гыйльманов әсәре турында мондый сүзләр әйтә: “«Албастылар» — татар әдәбиятында моңарчы күрелмәгән, яңа типтагы әсәр. Биредә тормыш чынбарлыгы белән мифология янәшә үрелеп барыла. Автор моңарчы әкиятләрдә генә телгә алына торган явыз көчләр, сихерчеләр, урман чытырманлыгында яшәүче албастылар белән укучыны йөзгә-йөз очраштыра, хәтта бераз куркыта, шомландыра да. Әсәрнең сюжеты шул дәрәҗәдә тыгыз корылган ки, һәр яңа бүлекне укыган саен вакыйгалар катлаулана бара, табышмаклар, сәерлекләр арткannan-арта...”[14]

---

11 Нигматуллина Ю.Г. “Запоздалый модернизм” в татарско литературе и изобразительном искусстве / Ю.Г.Нигматуллина. – Казань, 2002.

12 Хафизов С. Тамырлары үзебездә / С.Хафизов // Казан утлары. – 2006. - №8. – Б. 144-148.

13 Ибрагимов М.И. Миф в татарской литературе XX века: Проблемы поэтики / М.И.Ибрагимов. – Казань: Gumanitarya, 2003. – С. 47-51.

1. 14 http://adiplar.narod.ru/

Факил Сафин Галимҗан Гыйльманов турында мондый фикердә: “Прозада сирәк табыш — Галимҗан Гыйльмановның «Албастылар» романы. Әсәрне бер тында укып чыктылар. Галимҗан Гыйльманов — татар мифларын туплап, дөньяга чыгарып та милләткә зур хезмәт күрсәткән галим, әдәби тәнкыйтьтә яңа эз, яңа юнәлеш салган шәхес. Инде үзен прозада да уңышлы эшләрлек тормыш тәҗрибәсе булган, яшәеш агышындагы әхлакый-психологик моментларны дөрес тота һәм җиренә җиткереп тасвирлый алырлык автор итеп күрсәтте, образлы фикер остасы итеп танытты. «Албастылар»ны укыгач: гасыр башында Г.Рәхим, М.Хәнәфи тарафыннан нигез салынган модернизм үрнәгенә якын язуга уңышлы омтылыш ясалды, дип әйтә алабыз.”[15]

Шулай да әдипнең иҗаты, аерым алганда, “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнары сәнгати вакыт бирелеше ноктасыннан әле анализланмаган, өйрәнелмәгән. Ә без исә хезмәтебездә Галимҗан Гыйльманов иҗатында сәнгати вакыт бирелеше үзенчәлекләрен барлауны **максат** итеп куйдык. Максатыбыздан чыгып түбәндәге **бурычларны** билгеләдек:

1) сәнгати текстны өйрәнүгә багышланган хезмәтләрне күзәтү, төп юнәлешләрне билгеләү;
2) темпоральлек һәм хронотоп хакында нәзари мәгълүмат туплау;
3) Г.Гыйльманов шәхесе һәм иҗатына караган тәнкыйди мәкаләләр һәм фәнни монографияләрне барлау;
4) Г.Гыйльманованың “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнарында хронотопның бер компоненты булган сәнгати вакыт бирелеше үзенчәлекләрен ачыклау.

Хезмәтебезнең төп өйрәнү **объекты** булып Г.Гыйльмановның “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнары тора, тикшерү

2. [15] http://adiplar.narod.ru/

**предметын** исә шушы әсәрләрдәге сәнгати вакыт бирелеше үзенчәлекләре тәшкил итә.

**Методологик нигез** буларак Д.Ф.Заһидуллина, Т.Ш.Гыйләҗев, Ә.М.Закирҗановларның “Татар әдәбияты. Теория. Тарих”, Л.Г.Бабенконың “Лингвистический анализ художественного текста”, Л.Г.Новикованың “Лингвистическое толкование художественного текста”, “Художественный текст и его анализ” кебек хезмәтләренә таяндык.

Максат-бурычларыбызга ирешү барышында хезмәтебез түбәндәге **структурада** оешты.

1. Кереш. Бу өлештә хезмәтнең актуальлеге, теманың өйрәнелү дәрәҗәсе, максат-бурычлары, тикшерү предметы, объекты, методологик нигезе билгеләнде.

2. “Тел белемендә сәнгати текстны өйрәнү юнәлешләре”. Бу бүлек ике бүлекчәдән тора. “Сәнгати текст өйрәнү үзенчәлекләре” дигән бүлекчәдә әлеге өлкәгә караган төп хезмәтләргә нигезләнеп, текстны филологик анализлау үзенчәлекләре барланды. “Сәнгати вакытны өйрәнү үзенчәлекләре” бүлекчәсе әсәрдә урын-вакыт һәм аның бер компоненты булган вакытны анализлау юлларын тәкъдим итә. Шулай ук вакыт төшенчәсе белән бәйле темпоральлек категориясе хакында да нәзари мәгълүмат китерелде. Гомумән, бу бүлектә сәнгати вакыт төшенчәсе ачыкланып, хезмәтнең методологик нигезе эшләнде.

3. “Г. Гыйльманов иҗатында сәнгати вакыт төшенчәсенең лингвистик чаралар белән бирелеше” дигән бүлектә әдипнең “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнарына максатчан анализ ясалды һәм сәнгати вакыт бирелешенең төп чаралары аерып чыгарылды.

4. Йомгак өлешендә гомумиләштерелгән нәтиҗәләр эзлекле тәртиптә урнаштырылды.

## Беренче бүлек

# ТЕЛ БЕЛЕМЕНДӘ СӘНГАТИ ТЕКСТНЫ ӨЙРӘНҮ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ

### 1.1. Сәнгати текст өйрәнү юнәлешләре

Бүгенге лингвистик тикшеренүләрдә текст һәм аның белән бәйле проблемаларны тикшерүгә зур урын бирелә. Текст лингвистикасының үсеше XX гасырның 60-70 елларында башлана.[16] Хәзерге вакытка караган хезмәтләрдә исә текстның аерым аспектлары карала, анализлар китерелә. Аерым алганда, текст философиясен төзү омтылышы ясала (Руднев, 2000), текстның типологик характеристикасы эшләнә (Бабенко 1999, Белянин 2000), тестны аңлау проблемалары карала (Крюков, 1997, Галеева 1999, Залевская 2001, Сорокин 2003).

Сәнгати текстны өйрәнү аның структур һәм семантик үзенчәлекләрен анализлауны күздә тота. Текст семантикасын анализлаган хезмәтләрдән классик үрнәк буларак А.И.Новиков монографиясе күрсәтелә ала. Галим биредә текстның тышкы һәм эчке формасы мәсьәләләрен карый. Тышкы форма төшенчәсе астында тел чаралары берлеге карала, ә эчке форма дип кеше аңында тышкы форма берәмлекләреннән килеп туган уй-фикерне, аң эшчәнлеген атый.[17] Экспериментель анализлардан соң, текст эчтәлегенең аңлау процессының нәтиҗәсе булуы ачыклана. Текстның тышкы формасын барлыкка китерә торган тел берәмлекләреннән аның мәгънәсенә күчеш әлеге берәмлекләрне “уку”, төшенү, аларны реаль чынбарлык белән янәшә куеп карау һ.б. бик күп факторларга бәйле рәвештә тормышка ашырыла.

---

[16] Николаева Т.М. Лингвистика текста. Современное состояние и перспективы / Т.М.Николаева //Новое в зарубежной лингвистике. Вып. 8. – М.: Прогресс, 1978. – С. 5.

[17] Новиков А. И. Семантика текста и ее формализация / А.И.Новиков. – М.: Наука, 1983. – С.5.

Димәк, текстның эчке һәм тышкы формасы булу турындагы фикер сәнгати текстны ике яссылыкта карарга мөмкинлек бирә.

Шушы ук фикер Л.Г.Бабенко хезмәтләрендә дә үстерелә. Галимнең текст лингвистикасына караган күпсанлы хезмәтләрендә сәнгати текстка филологик анализ ясау мөмкинлекләре барлана.

Татар галимнәре тарафыннан әдәби текстны эчтәлек һәм форма берлеге ягыннан анализлау-тикшерү омтылышы ясаган хезмәтләр дөнья күрә башлады. Әлеге проблеманы стилистика белән бәйле яктырткан галимнәрдән В.Х.Хаков, Х.Курбатов, С.Ш.Поварисов, И.Бәширова кебекләр сәнгати текстның сурәтләү чаралары белән баетылуын, стилистик алымнарның эчтәлекне баету мөмкинлеген тикшерәләр.

Соңгы елларда дөнья күргән “Татар әдәбияты. Теория. Тарих” хезмәте (авторлары – Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанова, Т.Ш.Гыйләҗев) да сәнгати текстны эчтәлек һәм форма бөтенлеге итеп карый. Әлеге хезмәттә күренгәнчә, әдәби әсәрдә эчтәлек һәм форма бөтенлеге сакланырга тиеш. Әсәрнең эчке (эчтәлек) һәм тышкы ягы (эчтәлекне белдерү өчен хезмәт итә торган чаралар һәм алымнар) бер-берсенә җайлашкан, аерылгысыз була.

Эчтәлекне язучының укучыга нәрсә әйтергә теләве, җиткерергә теләгән фикерләре, тирә-юньгә мөнәсәбәте дип карасак, форма ничек әйтү, ягъни эчтәлекне белдерү һәм укучыга тәэсир итү өчен кирәк. Язучы башта – эчтәлекне, аннары форманы таба, укучы исә башта форманы кабул итә, аннары эчтәлеккә төшенә.[18]

Димәк, сәнгати текстны өйрәнү ике юнәлештә алып барыла: аның тышкы формасын барлыкка китергән элементлар һәм шушы элементлардан туган мәгънәне – эчке форманы анализлау.

---

[18] Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б 8-9.

## 1.2. Сәнгати вакытны өйрәнү үзенчәлекләре

Әдәби әсәр – язучы тарафыннан уйлап табылган яки яңадан тергезелгән тормыш-чынбарлык моделе. Әлеге модель без яши торган тормышка охшаган була яки аннан нык аерылып тора, ләкин һәр очракта укучы көткән яки аның өчен көтелмәгән тормыш ситуацияләре тудырыла.[19] Шуңа бәйле рәвештә әдәби әсәр тормышта очрый торган һәм укучы күңелен борчыган мәсьәләләрне калкытып куя, авторның әйтергә теләгән фикерләрен җиткерү мәйданына әйләнә. Һәрбер әсәрнең сәнгати кыйммәте дә шул үзенчәлекләр белән тыгыз бәйләнештә карала. Тормыш моделен торгызу исә билгеле бер урын-вакыт (хронотоп) мөнәсәбәтләреннән башка мөмкин түгел.

Хронотоп сюжетны төгәлләштерә һәм шартлылыгын тәэмин итә.Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт, гадәттә, бергә табыла. Төгәл билгеләнә торган урын-вакыт яки абстракт урын-вакыт була ала. Әсәрдә өч төрле вакыт бирелергә мөмкин: тарихи вакыт, вакыйгалар вакыты, перцептив вакыт (хикәяләүче яки персонаж вакыты). Урын исә – шәһәр, авыл, ил, табигать кочагы, экзотик урыннар, өй, бүлмә, больница  һ.б. Аның ачык һәм ябык булуын, чикле яки чиксезлеген,  реаль яки шартлы бирелешен билгеләргә мөмкин. Кайвакыт абстракт  һәм  төгәл  урын-вакыт бергә  килә.[20]

Урын-вакыт төшенчәсен киңрәк планда күз алдына китерү өчен, без терминнар һәм аңлатмалар энциклопедиясенә мөрәҗәгать иттек. Әлеге төшенчәне аңлату Бахтин фикерләренә нигезләнеп төзелгән. Хронотоп (урын-вакыт) – грек теленнән килеп кергән термин, матур әдәбиятта урын һәм вакытның үзара бәйләнешләрен билгеләү өчен кулланыла.

---

[19] Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – Б. 7.

[20] Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы / Д.Ф.Заһидуллина. — Казан: Мәгариф, 2004.— Б. 228.

“Хронотоп (грек. choronos – вакыт, topos – урын) – табигый фәннәрдән алынган һәм әдәбиятка Бахтин тарафыннан кертелгән төшенчә. Ул әдәбиятта сәнгатьчә эшкәртелгән һәм үзләштерелгән вакыт һәм пространоство мөнәсәбәтләрен белдерү өчен хезмәт итә. Галим әлеге төшенчәнең тел формалары белән бәйлелеген дә кире какмый. Әдәби хронотопның характерлы билгесе, Бахтин фикеренчә, түбәндәгедән гыйбарәт: биредә вакыт тыгызлана, сәнгатьчә күренә торганга әйләнә, ә пространство вакыт, сюжет һәм тарих хәрәкәтенә кушылып китә.[21]

Шулай ук А.Я.Эсалнек та бу турыда үз бәя-хөкемнәрен белдерә: “Соңгы вакытларда әдәби әсәрне анализлауда хрнонотоп төшенчәсенә әһәмият бирү күзәтелә. Ул вакыт һәм пространство бердәмлегеннән гыйбарәт. Пространанство – персонажларның яшәеше белән бәйле урын. Ә вакыт – бердән, тарихи вакыт, икенчедән, реаль, геройлар тормышының көндәлек вакыты, өченчедән, хикәяләү вакыты.[22]

Урын һәм вакыт әдәби текстның аерым компонентлары рәвешендә башка мөстәкыйль кисәкләр белән эчке бәйләнешкә керәләр, әдәби әсәрнең структур-семантик эшләнешендә зур роль уйныйлар. Әдәби вакыт һәм әдәби пространство (урын), хәзерге әдәбият белемендә махсус тикшерүне сорый торган проблема буларак, үз хокукын яулый. Текст эчендәге кисәкләр, берәмлекләр, берсе икенчесен алмаштырып килүче механик рәвештә өелгән баскычлар түгел, аларның диалектик яшәеше, эчке бәйләнешләре бик үзенчәлекле. Нәкъ менә шул бәйләнешне күз алдына китерү өчен, әдәби вакыт белән әдәби пространство мәсьәләсен анализлау кирәк тә. Ул – әдәби образ кебек, яисә пейзаж, сюжет кебек, күзгә бәрелеп тора торган элемент түгел. Әдәби вакыт белән әдәби

---

21 Литературная энциклопедия терминов и понятий / Под ред. Николюкина. Институт науч. Информации по общественным наукам РАН.— Москва: НПК “Интелвак”, 2003.— С. 1173.

22 Эсалнек А.Я. Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: Учеб. пособие. / А.Я.Эсалнек. – Москва: “Флинта”: Наука, 2004. – С. 89.

пространство үзара тыгыз бәйләнгән булып, алар бер бөтенне тәшкил итәләр. Бу берлек хронотоп дип йөртелә. Вакыт белән урынның характеры әдәби әсәрдә төрле юнәлештә килергә мөмкин. Аларны анализда аерып куеп, башка компонентлар белән нинди мөнәсәбәттә булуын ачыклау өчен, вакыт билгеләрен өйрәнү таләп ителә.

Хронотоп һәр милләт яки халыкның дөньяга караш үзенчәлеген табарга ярдәм итә. Әйтик, шәркый фикерләү тибы рухның материядән өстенлеге хакындагы күзаллауга нигезләнә (вакыт киләчәктән бүгенгегә ага), бу вакытның пространство белән чагыштырганда беренчеллегенә, кеше язмышының үзгәрмәс, алдан билгеләнгән булуына, тормышны үзгәртергә теләүнең мәгънәсезлегенә ишарә ясый. Гареп кешесе күзаллавында исә материя беренчел, вакыт бүгенгедән киләчәккә ага, ихтыяр һәм омтылыш көченә ия шәхес үз язмышына үзе хуҗа[23].

Хронотопны анализлау әдәби әсәрне вакыт-урын бирелешен тикшерүнең бердәнбер юлы түгел. Әдәбиятта вакыт һәм урын тәңгәл булмаганга, аларны аерым-аерым күзәтү дә әһәмиятле. Моннан тыш, болай карау сәнгатьнең үзенчәлекле сыйфатларыннан булган, вакытны – урын аша, урынны вакыт ярдәмендә белдерүне ачыкларга мөмкинлек бирә[24].

Без тикшерә торган Г.Гыйльмановның “Албастылар” әсәрендә вакыт һәм пространство бирү кызыклы. Пространство монда берничә дәрәҗәле. Беренчедән, ул реаль чынбарлык масштабындагы авыл. Бу җәһәттән ул ябык пространство. Икенчедән, авыл җире, кайчандыр серлелек белән тулган табигать кешеләр тарафыннан үзләштерелә, ә табигатьнең тирән серләрен белгән карчыклар яшеренергә тырыша. Параллель дөнья рәвешендә бирелгән албастылар утары пространствосы ачык, чөнки ул һәрдаим үзгәреп тора.

---

23 Заһидуллина Д.Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д.Ф.Заһидуллина, М.И.Ибраһимов, В.Р.Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005. – Б. 53.

24 Шунда ук. – Б. 54.

Г.Гыйльмановның “Оча торган кешеләр” романында вакыйгаларның үзәген тотып торучы төп урын бар. Без аны “вакыйга бишеге” дип атыйбыз. Монда вакыйга үстерелгән җир – тау; ул вакыт һәм пространствоның үрелеше булган хронотоп белән этносның үзара тәэсирен һәм бәйләнешен төшенү үзәге буларак чыгыш ясый.[25]

Хронотопны анализлау әдәби урын һәм вакытның түбәндәге төрләрен аеруны күздә тота:

1. Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның урыны һәм вакыты. А.Б. Есин реаль (сюжет) һәм әдәби вакытны аера, соңгысы – әдәби әсәрнең барлык вакыт аралыгын, хәтта әсәрдә атап үтелгән вакытны колачлый, реаль вакыт исә нульгә тигез (ягъни вакыйгасыз) тасвирларны да белдерә.

2. Тарихи урын һәм вакыт, яки әдәби вакыйгаларның гомуми иҗтимагый-тарихи атмосфераны сыйфатлаучы, персонажлар эш-гамәлләрен, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне билгеләүче, еш кына герой шәхесе формалашуга хәлиткеч тәэсир ясаучы объектив фоны.

3. Психологик урын һәм вакыт психологик процессларны һәм персонажларның субъектив хронотобын тергезү белән бәйләнгән. Р.А.Зобов һәм А.М.Мостепаненко бу хронотопны перцептуаль дип атый. Перцептуаль урын һәм вакыт, беренче чиратта, кеше психикасы һәм кешенең башкаларга, шулай ук табигатькә эмоциональ мөнәсәбәтле үзенчәлекләрен күздә тота.[26]

Хронотоп әдәби әсәрләрнең төр һәм жанрына бәйле дә үзенчәлекле була. М.Бахтин жанрлар аерымлануында хронотопның әһәмиятле роль уйнавын ачыклый. Мәсәлән, романның төп жанрлык хасиятләрен Бахтин романны эпостан аерып торучы “вакыт иерархиясе”нә мөнәсәбәтле күзәтә. Роман хронотобының даими нигезен төгәлләнмәгән хәзергегә йөз тоту

25 Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. Галимҗан Гыйльманов иҗатына штрихлар / Алсу Шәмсутова. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. - 66б.

26 Зобов Р.А., Мостепаненко А.М. О типологии пространственно-временных отношений в сфере искусства / Зобов Р.А., А.М.Мостепаненко // Ритм, пространство т время в литературе и искусстве. – М., 1974. – С. 14.

тәшкил итә, ә эпос хронотобы мәҗбүри рәвештә үткәнгә карый.[27] Драма хронотобының нигезендә хәзерге вакытка юнәлгәнлек, тамашачыда сәхнә хәрәкәтенең хәзер һәм монда баруы иллюзиясен тудыру ята. Катлаулы урын-вакыт бәйләнешләре лирик әсәрләрдә дә чагылыш таба.

Дөньяның урын-вакыт образын әдәби формадагы түбәндәге элементлар барлыкка китерә: сюжет – вакыйгалар агышы; характерлар системасы – кешенең җәмгыяви бәйләнешләре; пейзаж – кешене әйләндереп алган физик дөнья; портрет – кешенең тышкы кыяфәте; кертелгән эпизодлар – вакыйгаларга бәйле искә төшерелгән хәлләр. Шулай ук эчке мәгънә (подтекст) һәм тексттан тыш бәйләнешләр (сверхтекст) күзәтелергә мөмкин. Эчке мәгънә күренешләр арасында яшерен бәйләнешләр урнаштыра, әсәрнең күпкатламлылыгын тәэмин итә, мәгънәви баета. Тексттан тыш бәйләнешләр – авторның укучы белән яшерен сөйләшүе, ул укучыда төрле тарихи-мәдәни ассоциацияләр уятучы образлы “сигнал”лардан (эпиграф, ачык яки яшерен цитаталар, реминесценцияләр, исем-атамалар һ.б.) җыела, аларны әсәрдә сурәтләнгән әдәби чынбарлыкка “урнаштыра”.

Әдәби әсәрдә урын һәм вакытны анализлаганда, андагы барлык конструктив элементларга игътибар итәргә, һәрберсенең үзенчәлеген ачыкларга кирәк: характерлар системасын, сюжет төзелешен күзәтү, аерым сюжет элементларының күләмен чагыштыру; шулай ук пейзаж һәм портрет характерын ачыклау; эчке мәгънә яки тексттан тыш бәйләнешләр булу-булмауны, аларның ролен билгеләү.

Вакыт төшенчәсе турыдан-туры грамматикадагы темпоральлек төшенчәсе белән бәйләнештә тора. Фигыль заманнары белән бәйле бу категория лингвистикада зур урын алып тора. Татар телендә өч заман бар: үткән, хәзерге һәм киләчәк заман. Аларның 9 формасы була[28].

---

27 Бахтин М. М. Вопросы литературы и эстетики / М.М.Бахтин. – М., 1975. – С. 456-457.

28 Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2006. – Б.295.

Заман категориясе, гомумән билгеләгәндә, эш-хәлнең сөйләү моментына мөнәсәбәтен белдерә. Сөйләү моменты белән тәңгәл килгән эш – хәзерге заман, сөйләү моментына кадәр үтәлгән эш – үткән заман, сөйләү моментыннан соң үтәләчәк эш киләчәк заман була[29].

Татар телендә вакыт төшенчәсенең концептуаль кырын ачыклаганга кадәр, вакыт мәгънәсен белдергән сүзләрне тупларга кирәк. Билгеле булганча, вакыт - абстракт төшенчә, димәк, вакытны белдерә торган сүзләр конкрет мәгънәле сүзләрдән күпкә соңрак, кешелек цивилизациясенең предметлы фикерләүдән абстракт фикерләүгә күчү дәверендә генә барлыкка килгәннәр, шуңа күрә күпчелек халыкларда вакытны кисәкләргә бүлгәләү, вакытны санау астрономик җисемнәр – кояш һәм ай белән бәйли. Элек-электән вакытны билгеләү өчен халыклар физиологик халәткә, хезмәт итү, көнкүреш, дини ориентирларга таянганнар, телдә әлеге ориентирларга бәйле сүзләр, сүзтезмәләр барлыкка килгән, мәсәлән, ахшам вакыты, сабан, урак өсте һ.б. Татар телендә мондый сүзләр бик күп: мизгел, секунд, минут, сәгать, таң, иртә, кич, көндез, өйлә, төштән соң, кич, төн, көн, тәүлек, кичә, бүген, өченчекөн, атна, ай, яз, җәй, көз, кыш, ел, быел, былтыр, йөз, чор, гасыр, заман, дәвер, вакыт, мәңгелек. Алардан ясалган сүзләр: бишъеллык, унъеллык, йөзъеллык, меңъеллык. Кеше гомере белән бәйле сүзләр: сабыйчак, балачак, бала-чага, үсмерчак, яшьлек (яшь чак), яшь-җилкенчәк, егет чак, кыз чак, ир уртасы, картлык, гомер, тормыш.[30]

Сөйләү моментына карата билгеләнгән вакыт абсолют вакыт дип аталып йөртелә, ә шул вакытны белдерә торган фигыль формалары абсолют вакыт формалары дип билгеләнә[31].

---

29 Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. Югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек. / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2001. – 219 б.

30 Фәнни язмалар. Матур әдәбият телендә темпоральлекне белдерү чаралары/ Кузьмина Х.Х. - Казан, 2007. - 157-160 б.

31 Шанский А.М. Морфология современного русского языка / А.М.Шанский. – М.: Наука, 1970. – С.195.

Абсолют вакыт чагыштырмача вакытка каршы куела. Чагыштырмача вакыт – ул бер эш яки хәлнең икенче эш яки хәлгә карата үтәлү вакыты[32]. Мәсәлән: *Мин кионга **бардым**, әмма сеанс икенче көнгә **күчерелгән иде**. Кыз кибеткә **килде**, әмма ул **ябылып өлгергән**. Кайчан кояшлы матур көннәр **башлана**, шул вакытта без печәнгә **төшәчәкбез**.*

Һәрбер фигыль, аерым кулланылганда, абсолют заман формасына ия була, чагыштырмача заман мәгънәләрен алар билгеле бер синтаксик конструкцияләрдә кулланылганда алалар.

Алда билгеләп үтелгәнчә, татар телендә өч заман бар. Алар исә үз эчләрендә тагын тугыз формага бүленәләр: билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыль, билгесез (нәтиҗәле) үткән заман хикәя фигыль, тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыль, күптән үткән заман хикәя фигыль, кабатлаулы үткән заман хикәя фигыль; хәзерге заман хикәя фигыль; билгеле (категорик) киләчәк заман хикәя фигыль, билгесез киләчәк заман хикәя фигыль һәм киләчәк-үткән заман хикәя фигыль[33].

Һәр заманга мисаллар китерик.

Үткән заманның төрләре:

*Кунаклар соң гына **кайтып киттеләр*** (билгеле (категорик) үткән заман хикәя фигыль).

*Марат кичә имтиханын "бишле"гә **биргән*** (билгесез (нәтиҗәле) үткән заман хикәя фигыль).

*Ул безгә еш **килә иде*** (тәмамланмаган үткән заман хикәя фигыль).

*Әни күптән инде **пенсиягә чыккан иде*** (күптән үткән заман хикәя фигыль).

*Ул безгә кунакка еш **килә торган*** **иде** (кабатлаулы үткән заман хикәя фигыль).

Хәзерге заман:

---

[32] Шунда ук. – 195б..

[33] Татар грамматикасы: 3 томда. – М., Казан, Т.2: Морфология. – 2002. – 310б.

*Марат гел “бишле” билгеләренә генә* ***укырга тырыша***.

Киләчәк заман хикәя фигыльнең төрле төрләренә мисаллар:

*Иртәгә без татар теленнән* ***имтихан бирәчәкбез*** (билгеле киләчәк заман хикәя фигыль).

*Бер елдан инде бу турыда күләп* ***искә алырбыз*** (билгесез киләчәк заман хикәя фигыль).

*Малай аннан соң безгә кунакка* ***киләчәк иде*** (киләчәк-үткән заман хикәя фигыль).

Әлеге фигыль формаларының сәнгати текстта үз урыны бар, алар, төп мәгънәләреннән тыш, күчерелмә (синтагматик) мәгънә дә белдерә алалар. Шул рәвешле, темпоральлек категориясе сәнгати вакыт төшенчәсен оештыруда катнашучы төп компонентларның берсе булып тора.

Сәнгати текстта вакыт бирелешенең лингвистик чараларын тикшерү исә өч юнәлешкә бүлеп карала ала:

- вакыт төшенчәсенең төрле сүзләр белән бирелүе,
- вакытны грамматик формалар белән белдерү,
- вакытны график чаралар ярдәмендә тәгъбир итү.

Димәк, әдәби әсәрнең хронотобын анализлау әсәр төзелешен генә ачыкларга түгел, ә бәлки идеясен билгеләргә, эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирә.

## Икенче бүлек

# Г.ГЫЙЛЬМАНОВ ИҖАТЫНДА СӘНГАТИ ВАКЫТ ТӨШЕНЧӘСЕНЕҢ ЛИНГВИСТИК ЧАРАЛАР БЕЛӘН БИРЕЛЕШЕ

## 2.1. Вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр

### 2.1.1 “Албастылар” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр

Максатчан эзләнүләребезне дәвам итеп, Г.Гыйльмановның “Албастылар” әсәрендә сәнгати вакыт бирелешенең үзенчәлекләренә игътибар бирик.

2001 нче елда беренче мәртәбә басылып чыккач ук, әлеге әсәр күп кенә әдәбият галимнәренең игътибарын җәлеп итте. Фәнни дискуссиянең төп предметы булып “Албастылар”ның иҗат юнәлешен билгеләү торды. Д.Ф.Заһидуллина үзенең рецензиясендә әсәрне постмодерн үрнәге буларак тикшерсә, Й.Г.Нигъмәтуллина аннан модернистик билгеләрне таба.

“Албастылар” сюжетында реалистик һәм фантастик хикәяләү бергә үрелеп китә. Беренче, төп сюжет сызыгы армиядән кайткан Хәлим исемле авыл егетенең тормышы хакында сөйли: аны әнисе, авылдашлары белән мөнәсәбәтләрдә күрсәтә, өй салуын, өйләнүен, хатыны югалтуын бәян итә, һәм, нәни кызын ияртеп, туган авылыннан чыгып китү белән тәгәлләнә.[34] Икенче өлештә Хәлимнең Нәфисә белән бәйле язмышы урын ала.

---

[34] Заһидуллина Д.Ф. “Албастылар” яки татар прозасында яңа сыйфатлар / Д.Ф.Заһидуллина // Казан утлары. – 2001. - №11. – Б. 114.

Икенче – мифологик сюжет сызыгы Хәлимнең албастылар утарында булган вакытын үз эченә ала һәм мифопоэтик структурага корыла. Мифопоэтик схемага буйсындырылып, ул мифологик сюжетка хас герой тарихының бер-бер артлы килгән баскычларын күрсәтә: аның могҗизалы тууы, маҗаралары, өйләнүе, гадел идарә итүе һәм серле үлеме. Төрле халыкларның фольклоры мондый образлар турында фикер йөртә: грекларда – Тесей, Геракл, русларда – баһадирлар, төрки халыкларда – Алып һәм башкалар. Галимнәр фикеренчә, героик миф нигезендә ике мөһим вакыйга ята: дөнья барлыкка килү һәм шәхес үсеше.[35] Бу әсәрдә дә ике дөньяны бәйләп торучы герой буларак Хәлим чыгыш ясый. Аның тормышы миф геройларыныкы төсле корыла. Әсәрдәге мифологик мотивларның күплеге андагы сәнгати вакыт үзенчәлекләрен дә серле һәм әкияти характерда итә, укучыны шуның белән кызыксындыра да. Роман дәвамында вакыт җепләренең буталып, чуалып беткән төеннәрен чишү автор җиткерергә теләгән яшәеш хакыйкатен “укырга” мөмкинлек бирә.

Күренекле тел галиме Ф.С. Сафиуллина “Албастылар” әсәренә мондый сүзләр белән бәя бирә: “Стиле, теле ягыннан аерылып торган, татар прозасы өчен бөтенләй яңа булган «Албастылар» әсәре дә хәтергә уелып калды. Г.Гыйльманов язганга күрәдер дип уйлыйм. АньШ элегрәк шөгыльләнгән фәнни проблемасы да татар мифлары иде бит. Шул дөньяга тирән үтеп керүе аның фантазиясенә гаҗәеп үзенчәлекле импульс биргәндер дип уйларга нигез бар. Теле бай, хикәяләве гаҗәеп серле, сихерле-могҗизалы әсәр куркыта да, әмма аны укыйсы да килә; текст артындагы символик мәгънәләрне дә тоясың кебек... Бу әсәрдә таләбе гаять төгәл үтәлгән. Әсәр укыла, мавыктыра, күңелне кузгата... Мондагы кебек стилистик үзенчәлекле серле сүзләрнең концентрациясен беркайда да укырга туры килмәгән иде әле.”[36]

---

[35] Давлетшина Л.Х. Мифологическая основа сюжета романа Г.Гыйльманова “Албастылар” / Л.Х.Дәүләтшина // Яшь галимнәр карашы. – Казан: Школа, 2006. – Б. 27.

3. [36] http://adiplar.narod.ru/

Әсәрдә вакыт төшенчәсенең аерым сүзләр белән бирелүе турыдан-туры тел яссылыгында укучыга вакыйгаларны күзәтеп барырга, аларга бәя-мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. Әсәрдә вакытның күптармаклы булуы күзгә ташлана: биредә үткәндәге ретроспектив вакыт та, геройларның бүгенгесен тасвирлау да, киләчәгенә күз салу да бар. Вакыйгалар вакытының башлануын автор түбәндәге лексик берәмлекләр белән бәян итә:

*“Июль ахыры.*

*Чиллә күзе.*

*Олы юл.”*[37]

Әлеге юллардагы *июль ахыры* берәмлеге әдәби вакытны белдерә. Ул *чиллә вакыты* лексик берәмлеге белән тагын да төгәлләштерелә. Шул рәвешле, вакыйгалар җәйнең үзәгендә башланып китә. Һәм чиллә вакыты әсәрдә әледән-әле кабатланып тора, сәнгати вакытны мистик вакыйгаларга бәйле оештыручы ниндидер бер серле төшенчәгә әйләнеп китә:

*“Хәлим дертләп уянып киткәндә, һаман шул күренеш иде: күз күреме җирдә басу, басу артында яшел тасма сузылган – анысы урман; күк аяз, көн якты, чиллә...”* (14 б.)

Бу җөмләдәге *чиллә* берәмлеге, календарь вакыт булудан үсеп, вакытның бер мизгелдә туктал калуын җиткерә.

*“Бәй, теге вакытта, мин бала тапканда да, ике кара хатын булышкан иде... Ай Аллам, шулар гына харап итте микәнни сине, балам? Алар бит ел саен эссе чилләдә авыллар аша узалар.”* (28 б.)

Әлеге җөмләдә исә җәй вакыты белән бәйле *чиллә* компоненты төгәлләштерелә төшә һәм кабатланучы күренешне белдерә.

Әсәрдә әледән-әле юл образы калкып чыга. Роман үзе үк юлдан атлап баручы Хәлимне сурәтләү белән башланып китә. *“Олы юл. Урман аланнарына кирә-кирә бормаланып сузылган бу таш юл, очы-кырые булмаган*

---

[37] Гыйльманов Г. Албастылар: Хыялый кыйсса / Г.Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – Б. 5. (Моннан соң мисалларның бит саны җәяләр эчендә генә күрсәтеләчәк).

*мари урманнарын урталай кисеп, алга йөгерә дә йөгерә. Барасы җир күп калмадымы әле дигән кебек, ул ара-тирә калкулыкларга килеп менә, биегрәк таулар очраса, хәл-егәрлеген юкка сарыф итмәс өчен, иренмичә әйләнеп уза. Мари урманнарының шомлы көе дә һич куркытмый аны. Хәтта юл белән урман бер-берсенә шулкадәр береккән, бәйләнгән кебек, юлны урман "биленнән" чишеп ташласаң, мәһабәт имәннәр, озын, төз чыршы-наратлар, шау-шулы усаклар авып, имгәнеп, төрле якка таралып бетәрләр кебек тоела."* Юл образы әсәрне каймалап ала, автор аны җанлы итеп тә, сынаулар барган, Яхшылык белән Явызлык көрәше дәвам иткән урын буларак та сурәтли. Әлеге юл очсыз-кырыйсыз *("Бу юлның берәр очы-кырые булыр микән? Юлның очы булмый, ди халык")*. Юл – язмышлар очраша торган урын ("*Чөнки юл – язмышлар очраша торган урын. Һәм, иң мөһиме, юлсыз урман, урмансыз юл юулмый"*). Юл романны каймалап ала. Әсәр ахырында Юламан картның икенче бер юлчыга юл күрсәтүе юлдагы хәрәкәтнең мәңгелек булуы турында сөйли. Шул рәвешле, *юл* сүзе, *юл* образы вакытның чиксезлеген белдерүче лингвистик чарага әверелә. Бирердә мизгел белән мәңгелек очраша, Вакыт тукталып калган кебек була: *"...Бу юлның берәр очы-кырые булыр микән? Юлның очы булмый, ди халык. Инде олы бер гомер барган кебек Хәлим. Вакытның чамасы онытылды. Дөресрәге, Вакыт тәгәрмәче бөтенләй туктап калгандай булды. Кояш һаман шунда – бер урында. Коймага менгәч, күлмәге кадакка эләгеп, асылынып калган авыл малае кебек, ул һаман бер ноктамсында тора."* (10 б.) Әнә шулай, юл чиксезлек турында уйланырга этәрә.

Хәлимнең районнан кайту юлы; албастылар утарына алып баручы, авылдан урманга илтүче, карчыкларны авылга алып килүче, Сания Хәлимне тапкан юл; онытылган догаларны искә төшерергә мәҗбүр иткән юл; хакыйкатьне аңлау яки албастыга әверелү юлы; саташып аң төпкеленә сәяхәт итү юлы һ.б. Башланган урыны да, тукталган җире дә юк аның. "*Юл бетү бит ул – тормыш бетү, гомер өзелү дигән сүз",* һәр кешенең яшәү юлы бар.

*“Юлы ерак аның. Күпме барасын ул үзе дә белми. Бер көн барырмы, бер атна, бер ай, берел барырмы? Әллә гомер буе барып та максатына ирешә алмасмы?”* Максатка ирешү юлы юкмыни? Ләкин аннан да зуррак юл – Яшәеш үзе: *“Явызлык та, изгелек тә юлга иялəшүчән була. Чөнки юл – язмышлар очраша торган урын. Һәм иң мөһиме, юлсыз урман, урмансыз юл булмый. Алар барыбер очрашалар. Алар очрашкан чакта башлана да инде яманлык белән изгелек көрше”.*[38]

“Хәлим егерме яшьләр чамасында булыр.” Төскә-биткә чибәр Хәлимнең берничә еллык гомерен колачлаган әсәр дә асылда аның олыгаю, өлгерү юлы буларак кабул ителә. Урман юлына ваемсыз бер егет булып кереп киткән Хәлим, нәтиҗәдә, акны карадан аерырлык, барыр юлын анык белгән кешегә әверелә.

Хәлимнең урман белән авыл арасында үткән юлы үз күңелендәге албастыларны җиңү буларак аңлашыла һәм борынгы чорларда киң таралыш тапкан инициация йоласы белән тыгыз бәйләнә. Балалар тиешле яшькә җиткәч, аларны ыруга тулы хокуклы әгъза итеп алу өчен, баланың физик һәм рухи мөмкинлекләрен ачыклау максатыннан үткәрелгән йоланың башкарылу урыны һәрвакыт урманда булган. Хәлим дә, нәкъ борынгы йоладагыча, урман йортында сынаулар үтә, тормыш хакыйкате белән таныша, мәрхәмәтле сабыр булырга өйрәнә, күңелендәге албастыны “агарта”.[39]

Әсәрдә Хәлимнең албсатылар утарына беренче тапкыр кереп чыгуы бер еллык вакытны үз эченә ала. Әмма башта егет моны хәтерләми, аңа бу ел булмаган кебек тоела, ул хәтерсез кала. Шул рәвешле, вакытның туктап калуы кеше күңелендәге тирән кичерешләрне күрсәтергә мөмкинлек бирә: *“Ниндидер башка дөньяга кереп чыккандай хис итте ул үзен. Ул дөньяда гүя вакыт бөтенләй башка тизлектә ага... Бер мизгелдә бер сәгатьлек, бер*

---

[38] Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачылык) / Заһидуллина Д.Ф. - Казан: Мәгариф, 2006. - 145б.

1. [39] Дәүләтшина Л.Х. Киләчәккә күз төбәп... / Л.Х.Дәүләтшина // Казан утлары. – 2005. - №9. – 158б.

*сәгатьтә бер еллык вакыт уза анда.”* (15 б.) Бу юллардагы *бер мизгел – бер сәгать, бер сәгать – бер еллык* берәмлекләренең дихатомик бердәмлектә бирелеше Хәлим яшәгән дөньяның катлаулыгын җиткерә, аның язмышын серле-томанлы итә.

Шул рәвешле, шушы бер ел гомер Хәлим язмышын вакыт ягыннан ике этапка бүлә. Автор аны *үткән* һәм *киләчәк* лексемалары аша җиткерә:

*“Үткәне убылып әллә кая киткән, ә киләчәге...”* (69 б.)

Гомумән, бу *бер ел* төшенчәсе әсәрдә олы мәгънәви функция белән тулыландырыла. Хәлим язмышының бер серле этабын тәшкил итсә, бер ел аның әнисе Саниянең кичергән хәсрәтләре кеше күтәрә алмаслык тоела:

*“И-и, балакаем... Бер ел буе, көне-төне түккән күз яшьләрем кайтарды бит син... Ходай Тәгалә.”* (19 б.).

Әсәрдә кеше язмышына бәйле вакыт төшенчәсе, гомумән, еш күзәтелә. Утарда дүрт яшеннән бирле гомер кичергән телсез әпәнең язмышы да вакытның фәлсәфи характерда булуын ассызыклый, әлеге фикер кырык ел рухи коллыкта яшәп, дүрт яшьлек сабый булып калаган кеше фаҗигасен күз алдына китереп бастыра:

*“Ул дүрт яшеннән шушында үскән, кол хезмәтендә яшәгән булырга тиеш. Нинди хәтәр язмышка дучар бу кеше!*

*Хәлим тагын шуны аңлады: Корбан исемле бу бәндәгә хәтерен кайтарырга ярамый.* ***Соң инде! Бик соң!*** *Йөрәге түзмәячәк... (...) Ул инде кол. Коллык – аның яшәү рәвеше.* ***Үткәне, бүгенгесе, киләчәге.”*** (265 б.)

Мисалларда калын шрифтлар белән бирелгән берәмлекләр Корбанның *дүрт ел* гомере белән каршылыкка керә.

Әсәрдә кеше кичерешләре белән бәйле вакыт образлары да еш кулланыла. Автор *төн – көн, яз – көз* һ.б. вакыт антиномияләрен яратып сурәтли. Төнлә һәрвакытта да шомлы вакыйгалар була, көтү хәсрәте, югалту ачысы, рәнҗү, каргыш – болар барысы да төн белән бәйле. Шул рәвешле,

вакытның төн лексемасы белән белдерелүе, гади пейзаж элементы гына булудан үсеп, фәлсәфи характер белән тулыландырыла:

*“Күктәге кояш та, көне буе галәмне яктыртып, җылытып торганнан соң, хәл алыр өчен* ***төнгелеккә*** *офык артына кереп китә. Үз улларын өзелеп көтүче аналарның күзләре генә бер минутка да йомылмый.”* (151 б.)

Майя үлгән төн дә шомлы һәм куркыныч: *“Майяга кайтмыйча ярамый. Өйдә аны гаиләсе, Гөләше көтә. Инде югалтып та бетергәннәрдер. Ашыгырга кирәк. Әллә ничек* ***төне дә шомлы, караңгы****... Йолдызлар да сирәк... Әнә бит, бүген алар бөтенләй күк йөзендәге кара болытлар хөкемендә калганнар.”* (185 б.)

Авылда яшәргә калган урман карчыкларын да милиция төнлә алып китә: *“Аларны, бер атнадан соң,* ***яңгырлы төндә*** *алып киттеләр.”* (368 б.)

Шул рәвешле, *төн* образының сәнгати вакыт төшенчәсен оештыруда роле зур. Аңа капма-каршы буларак, автор *таң* вакытын сурәтли. Таң хронотобы әсәрдә яңарыш, рухи бушану төшенчәләре белән бәйләнештә карала:

*“Бөтен күңел ачыгысын түгеп, чәчеп ташлар өчен, менә шулай* ***ачы таң белән*** *Ак бабай янына йөгереп керү кирәк булган икән...”* (160 б.)

*Кыш – яз* каршылыгы да кеше күңелендәге каршылыклары тасвирлау максатына хезмәт итә. *Көз* – рухи үлем, *Яз* – яңарыш янәшәлеге сәнгати вакыт бирелешен яңа төсмерләр белән баета:

*“****Яз*** *иртә килде. (...) Наратта бөреләр бүртте, усак, чаганнарның кәүсәләре дымлана башлады. Кошлар тавышына да ниндидер яңа аһәң, яңа мәгънә керде. Хәлимнең күңеле генә* ***кышкы*** *йокысында калды.* ***Көздән*** *карчыклар салып калдырган бозны эретерлек кояш чыкмаган иде әле аның түбәсендә.”* (92 б.)

Романда вакытның үткән – бүген аркылы киләчәккә юнәлгән кысаларда тирбәлүе үлеп терелү төшенчәсе белән дә әледән-әле укучы хөкеменә җиткерелеп тора. Бу – сәнгати вакытның мифологик күзаллаулар белән

бәйлелеген китереп чыгара. Бу әсәрдә албастылар утарында Хәлим үлем кичерә. Ул телен һәм хәтерен югалта. Утарда гомер кичерүче әпәләр дә хәтерсез һәм телсез. Алар билгеле бер инстинктларга гына буйсынып гомер кичерәләр. Алардан аермалы буларак, Хәлим яңадан "туа" ала. Гомумән, автор үзе үк, ачкыч сүзләр ярдәмендә, яңадан туу, үлеп терелү мотивы турында әсәр тукымасында берничә мәртәбә кабатлый. Хәлим үзе генә дә бу процессны берничә мәртәбә кичерә. Беренче тапкыр утарда хәтерсез калса, аннан соң авылда агач астында калып, хәтере кайта, үткәннәре исенә төшә. Утарда егетне үлемнән Майя коткара.

Хәлим бер ел югалып торганнан соң кайткач, әнисе Сания апа больницада түбәндәге сүзләрне әйтә: *"И-и, балакаем... Үлепләр терелдеңмени соң син? Кайларда гына йөреп кайтты икән бу башларың?".* (18 б.) Хәлим тарафыннан яңадан туу процессы авыр кичерелә: *"Хәлим тормышка авыр кайтты. Үткәндәге гомеренең һәр шаһиты белән очрашу күңелен тетрәндереп куя, җан-бәгыренә көтелмәгән җәрәхәтләр сала иде. Читтә йөреп кайту гына түгел шул,* ***үлеп, күмелеп, кабат якты дөньяга туып кайту*** *белән бер аның бу язмышы. Иң аянычлысы шул: ул үзенең бер еллык гомере хакында берни дә белми. Бер бөртек хатирә, бер мизгел гомер, гөлт итеп кенә булса да кабынып алган берәр күренеш, маҗара булсын иде дә бит..."* (37 б.)

Хәлимнең албастылар утарыннан, урманнан бөтенләйгә кайтуы да яңадан туу мотивына яраклаштырыла. Егет тормышка башка күз белән карый башлый, яшәешнең мәгънәсенә төшенә. Ул яшәвен дәвам итә, әмма бу инде элеккеге яшәү түгел. Аның күңеле чистарган, гамьсезлек пәрдәсе күзләрен томалаудан туктаган. Юлчыларның гомерлек юлдашы Юламан картның: "*Син үлмисең.* ***Син әле тудың гына. Яши генә башладың****",* – диюе дә шушы фикерне көчәйтә.

Яңадан туу мотивы Нәфисә язмышы белән дә бәйле рәвештә сурәтләнә. Ул гөнаһлы җан иясе, тормышында ходай тарафыннан кичерә алмаслык

җинаять кылган: Нәфисә Майя үлемендә гаепле. Шуның өчен ул җәза алган: аның баласы булмаячак. Тәкыя әби (албастыларның берсе) аңа, гөнаһын юу өчен, үлеп терелергә кирәк икәнлеген әйтә (“*Үз гөнаһыңны тану – максатка ярты юл ул. Калган яртысы кыенрак булачак. (...) Сиңа...* ***үлеп терелергә*** *кирәк.”* (345 б.) Янгын вакыйгасы, элекке мәгънәсен саклап, чистарыну чарасына әверелә. Нәфисә үлеп терелә. Ул яңа, гөнаһсыз кеше булып туа *(“Булачак балагыз, булачак. Ул инде* ***үлеп терелде...”*** (355 б.).

Шул рәвешле, яңадан туу мотивы әсәрдә берничә герой язмышына бәйле рәвештә карала һәм күңел чистарыну, рухи кыйммәтләрнең үзгәрүен аңлата башлый. Ул аларның тормышын вакыт ягыннан икегә бүлә һәм рухи чистарынып, гөнаһлардан арынып яшәүгә нигез булып тора.

Әнә шул рәвешле, “Албастылар” әсәрендә сәнгати вакыт бик күп төрле сүзләр, лексик берәмлекләр аша җиткерелә. Шулардан төп төшенчәләр буларак мизгел һәм мәңгелек берлеге, үткән – бүген – киләчәк триадасы сурәтләнә һәм хронотопны фәлсәфи эчтәлек белән баета.

### 2.1.2“Оча торган кешеләр” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән сүзләр

Хезмәтебезнең икенче объекты булып Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» исемле әсәре тора. Автор аны «иясез язмышлар хакында бәян» дип атый. Кеше урын һәм вакыт кисешкән ноктада яши. «Оча торган кешеләр» әсәрендә исә кешенең һәм аны борчыган сорауларның вакытка бәйләнешле сурәтләнүе белән очрашабыз. Язучы биредә вакыт агышын бирүдә төрле вакытта яшәгән ике эти белән улының бер үк мәсьәләләр хакында баш ватуларын бирү алымы ярдәмендә сиздерә. Автор Хөсни карт авызыннан авыл тарихын, әсәрне турыдан-турыга үтеп чыккан, сихри көчкә ия булган

Кала-тау тарихын, кайчандыр Чулпан йолдызыннан төшкән кешеләр турындагы хикәяләрен сөйләттерә.

Дөньяда ике нәрсә генә — *вакыт һәм мәңгелек*. Кеше җисми яктан мәңгелек түгел. Шуңа күрә Сәүбәннең этисе серне белә алмыйча үлә. Ягъни, автор бәхет-бәхетсезлек төшенчәләре турында уйлана. Бу җирдә үзеңә тиң парыңны тапсаң гына син бәхетле. Шул очракта гына синдә канат чыгып күккә оча алырсың дигән фикерләрне җиткерә автор. Ләкин этисе артыннан әлеге сораулар кала. Аларны ачыклау шөгыленә улы керешә. Әнә шулай кешелек өчен әһәмиятле фикер, җисми дөньяның кеше дигән аңлы заты яшәгән вакытта, буыннардан буыннарга тапшырылып, дәвамлы, «мәңгелек» яши. «Мәңгелек» сүзен куштырнаклар эченә алу аңлашылса кирәк, кешелекнең яшәве, ахыр чиктә, чын мәңгелектән (вакытның бервакытта да туктамый баруыннан) кыскарак, ул аның билгеле бер өлешен генә тәшкил итә. Җирдә тереклек яшәр шартлар бетеп, кеше юк була калса да вакыт һичнигә карамый алга таба агышын дәвам итәчәк, аның ахыры юк һәм аны күз алдына китерү дә мөмкин түгел.

Сәүбәннең авылдан чыгып китүенә *унсигез ел* узды. Шушы вакыт әсәрдә мәңгелек белән тиңләштерелә. Еллар дәвамында һәрнәрсә үзгәрә: җәмгыять, кеше холкы, кеше гадәте, кеше үзе, вакыт хәттә табигать үзгәрешендә дә эз калдыра. *(“Сәүбән чыгып киткәндә беләк калынлыгында калган бу агач хәзер әнә колачка сыярлык булып үскән”* (13б.). *(“Унсигез ел буе туган җирсез яшәп кара әле... Бер елы, бер көне дә саргайта аның. Унсигез ел бит, бер буын алмашынган гомер... Бер гомер...”* (75б.) Кеше үзгәрсә дә, аның хисләре һич тә үзгәрә алмый. *“Унсигез ел – күбрәк шул. Бу вакыт эчендә иң олы йөрәк тә күңел хисләрен түкми-чәчми саклап кала алмас иде, мөгаен. Хисләр шактый тузган... Ә менә сагыш шул килеш. Сәвиянең сагышы үзгәрмәде. Ун елда да, унсигез елда да саф, садә килеш калды...”* (140б.)

Әсәрдә кеше гомере мәңгелек белән чагыштырыла, һәм Сәүбәннең бала чагы тарафыннан болай сурәтләнә: *“Кеше гомере – мәңгелекнең кечерәйтелгән моделе генә. Ә мәңгелек үлми. Димәк, кеше дә үлми...”* (146б.)

“Татар теленең аңлатмалы сүзлеге” мәңгелекне түбәндәгечә шәрехли: “Башы да, ахыры да булмаган вакыт агышы”. Бу, - һичшиксез, дөрес, объектив, чын фәнни таләпләргә җавап бирә торган тирән мәгънәле лексик һәм фәлсәфи-мифологик аңлатма. Шул ук мәңгелек сүзенең сыйфат мәгънәсе бераз башкачарак аңлатыла: “Беркайчан да бетми торган, гомерлек”. Мәгълүм ки, Бу дөньяда беркемнең дә мәңгелек гомере булмый. Гомумән алганда, кеше гомере бик кыска! Шулай булгач, әле генә китерелгән аңлатманың ахырында кулланылган *гомерлек* сүзе аңлатманың беренче (дөрес) өлешен тулысынча юкка чыгара. Тик әлеге җөмләнең беренче өлешенә дә бер мөһим төзәтмә кертү кирәк: Беркайчан да башланмый һәм бетми торган”. Мәсьәләгә мифологик яссылыктан якын килсәк, тирәлек тә, мәңгелек тә – беркемгә дә һәм бернәрсәгә дә буйсынмый торган, чын мәгънәсендә объектив, үз ихтыярлары белән генә “яшәүче” категорияләр. Алар Җиһан – Космос – Галәм кебек атрибутлардан да өстен тора.[40]

Г.Гыйльмановның “Оча торган кешеләр” романында мәхәббәтне белдергәндә Сәвия мәңгелек төшенчәсен куллана, чөнки мәхәббәт олы хис буларак чиксез (*“Хуш, кадерлем минем, бүләгең өчен рәхмәт, мин **мәңгегә** синеке! Синеке генә!..”* (106б.)

Әсәрдә мизгел-мәңгелек каршылыгы күзәтелә (*“Гүзәллеккә соклану өчен бер мизгел җитә, гүзәллекнең үзен тудыру өчен гасырлар, дәверләр кирәк булган.”* (130б.)

Әсәрдә вакыт төшенчәсе шактый еш искә алына (*“Туган авылыннан чыгып киткәнгә дә әнә күпме вакыт үткән бит! Һәркемгә мәгълүм: Вакыт*

---

40 Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2т. (Д-С) / Фатих Урманче. - Казан: Мәгариф, 2009. - 219б.

*канатында сагыш бар (...) Вакытны да, хакыйкатьне дә күреп, тотып карап булмый...”* (17б.)

*Вакыт-гомер-тормыш-яшәү* төшенчәләре янәшә килеп, бер-берсен ачыклап, тулыландырып, бер-берсенә төгәлрәк мәгънә бирәләр кебек:

*“...Вакыт һәрвакыт алга бара. Аның артыннан өлгерә алмаганнар ялгыз кала. Сәүбән дә кайсыдыр мизгелдә вакыт арбасыннан төшеп калды, ахры.*

*...Үткән гомер үзенең максаты белән бәяләнә. Максаты белән мәгънәле ул. Сәүбәннең гомере максатсыз булды. Ә мәгънәсе булдымы?*

*...Гомер яшәвең белән түгел, яшәвеңне тоюың белән кызык. Сәүбән яшәде, әмма яшәвен тоймады.*

*...Яшәү – үзгәрү генә түгел, үз-үзең булып калу да. Сәүбән үзен югалта язды, ахры.*

*...Гомернең озынлыгы еллар белән түгел, кылган изгелекләр белән үлчәнә. Сәүбән начарлыклар кылып яшәмәде, әмма ул изгелекләр дә кылмады!*

*...Син яшәгән гомерне синнән башка беркем дә яши алмый.*

*...Һәр гомер үз язмышын иҗат итә. Бу иҗатның төп шарты – көрәш. Көрәш тукталдымы – гомер үлә башлый... Унсигез ел элек Сәүбән дә үз бәхете өчен көрәшүдән баш тартты. Тормыш агымына буйсынды. Вакыт белән Очраклылык ихтыярында калып, иҗаттан, көрәштән китте...”* (19б)

Алдагы автор сүзләреннән күргәнебезчә, бары тик тормышыңда максатың булса гына яшәешең мәгънәле булачак, шушы максатка ирешү ниятең белән тормыш юлыңны озынайтасың. Ә Сәүбән авылдан чыгып киткән вакытта ук үз максатыннан баш тартты. Моңа ул үзе дә төшенде дип әйтеп була *(“Сәүбән юлны бераз онытып та җибәргән, ахры. Ләкин бер нәрсәне ул төгәл белә: басу капкасыннан авылга кадәр шактый барасы... Бала чакта бу ара шундый ерак булып күренә иде, әле дә хәтерли, малайлар белән бу якларга бер мәртәбә генә килеп китеп була иде.”* (18б.). Басу капкасыннан авылга кадәр юл – балачакта максатлары булган Сәүбәннең

тормыш юлы. Ә *“бу якларга бер мәртәбә генә килеп китеп була иде”* дигән автор сүзләрендә, тормышны бер тапкыр гына яшәп була дигән мәгънә ята *(“...Гомерне ярты-йорты яшәп була, әмма аны ике мәртәбә яшәп булмый. Сәүбән дә үз тормышының ярты-йортысын яшәгән инде...”* (20б.)

Авылга кайткач, Сәүбәннең “канатлары үсте”. Моңа сәбәп булып яраткан кешесе белән очрашу, малаен табу, унсигез елдан соң Кала-тау белән уртак тел табу. *“Әйе-әйе, кешеләр тормышында шундый көннәр була – оча торган көннәр. Бу көннәрдә аларның язмышлары хәл ителә, тормышлары көтелмәгән урам-тыкрыкларга кереп китә, яшәүләре яңа мәгънә ала... Йөрәкләрендә яшәү дәрте уяна, күңелләренә сафлык, миһербанлык ягыла, күзләренә нур, беләкләренә егәрлек куна...”* (151б.)

Вакыт төшенчәсенә нигезләнеп әсәрдә *яшәү-үлем* оппозициясе яшәп килә. Автор аларның бер-берсеннән аерылгысыз булуларын әйтә *(“Үлем булмаса, яшәүнең мәгънәсе булмас иде. Ахыр чиктә, яшәү ул – бертуктаусыз үлеп һәм туып тору. Үлем белән яшәүнең дәрәҗәләре тигез – алар бер-берсеннән башка яши алмыйлар. Үлемнән курыккан кеше яшәүнең тәмен белми.”* (134б.)

*“Кешегә гомер бүләк итеп түгел, бурыч итеп бирелә. Сәүбәнгә дә бурычын түләргә вакыт, ә ул һаман бурыч җыеп йөри.”* (20б.). Автор шушы җөмләләр белән нәрсә әйтергә тели икән? Сәүбән үз бурычын үтәмәгән булса, димәк, ул бу гомерне, унсигез елын, бушка уздырган? Бу сорауга кем җавап бирә алыр? Әлбәттә, җаваплары бары Сәүбәндә генә, һәм ул бу мәсьәләне бала чагы, ягъни үткән гомере ярдәмендә чишәргә тиеш. *(“Кеше – шаккатыргыч дәрәҗәдә сәер зат. Байлыгы, малы китсә, җаны сызып борчыла, ә мәгънәсез үткән көннәре хакында уйларга вакыт тапмый. Сәүбәннең дә мәгънәсез үткән тормыш көннәре күп булды. Аның бу битарафлыгына ис-акыллар китәрлек... Басу капкасы төбендә очраган сәер малай исә аны, ниһаять, уйланырга мәҗбүр итте.”* (35б.) Гомернең мәңгелек булмавы турында автор мондый сүзләр әйтә: *“Гомер шушы факел*

*кебек ләса. Артык тиз чапсаң, ул гөлт итеп сүнәчәк... Сәүбән дә шундый хәлдә: тизрәк йөгермәсә – аны тау басачак, артык нык чапса – уты сүнәчәк...”* (132б.) *“Гомер дә тау кебек – озак менәсең, бик тиз төшәсең...”* (133б.)

Әсәр буе төп герой белән янәшә аның *бала чагы* бара. Бу образ – кешенең уткәннең,бүгенгесенең һәм киләчәкнең сурәтләнеше. Сәүбән үз бала чагына болай ди: “*Син минем бала чагым гына түгел, иманым да, күңел тынычлыгым да, өметем дә, киләчәгем дә...”* (48б.) Кешенең бала чагы киләчәккә юл ача, ярдәм итә (*“...бала чаклары кешеләргә аларның иң авыр чакларында, гомер юлларының иң кискен борылмаларын ураганда килә. Миңа да шундый вакытта килде бугай ул.”* (110б.) Ак бабай Сәүбәнгә бала чагы, яшьлеге турында мондый сүзләр әйтә:

– *Кеше үзенең гомерен мәңге яшәргә килгән кебек яшәргә тиеш. Үткәнеңне, бала чагыңны, яшьлегеңне онытма, алардан аерылма. Үткәнең сине саклап калачак. Унсигез ел иленә кайтмаган кеше – иң соңгы кеше, иң беткән кеше ул.”* (51б.)

Бала чагыннан башка, Сәүбәннең киләчәге-үткәне-бүгенгесе аның малаенда, Сәвия белән уртак балада чагыла. Улын мәгарәдән эзләгәндә, ул үзен эзләгән булып чыга һәм үзе дә моңа төшенә (*“Тизрәк уянырга иде бу төштән, барып табарга иде Сәүбәнне... Кызык әйтелде... Сәүбәнне... Әйе шул, ул үзен-үзе эзләп килде, һәм ул эзләгәнен табарга тиеш!”* (130б.)

Бала чакта кеше саф күңелле, җаны гөнаһка бирешмәгән әле. Вакыт узу белән генә кеше холкы да, кеше үзе дә үзгәрә. *“Үзең белән аралашкан кешедә бер генә уңай сыйфат та тапмасаң, син аның бала чагы турында уйла. Ул сиңа элеккечә ямьсез күренмәс” ,*(63б.) - дип әйтә автор.

Әсәргә *төн* образы да килеп керә. Курку хисе, рәнҗү, куркыныч, хәсрәтле хәлләр дә төн белән бәйле. Яшь чагында, унсигез ел элек Рәмис белән сугышу төнлә иде. Шушы төндә булган вакыйга Сәүбәннең унсигез ел гомерен тартып алган, аны үз бәхетеннән баш тартуга этәргән. Сәүбәннең

хастаханәгә эләгүе дә төнлә иде. Унбер ел элек Минзәлә педучилещесының “Чулпан” отряды Чаллыга килгән төнне, автор Сәүбәннең бәхетсезлеге башланган төн итеп билгели (*“Сәүбән ул кичне оныта алмады. Ниндидер серле, сихри төш булып, хәтеренә ягылып калды. Бу кичтә татыган назларын соңыннан башка кешеләрдән эзләде, таба алмады. Аның бөтен бәхетсезлеге дә шушы кичтән башланды, ахры...”* (107б.)

Романда *Кала-тау* образы автор тарафыннан тере җан иясе булып тәкъдим ителә. Аны автор алдан ук мондый сүзләр белән сурәтли: *“Әнә ул бер читтә, тонык кына шәүлә булып, артка таба шуыша. Уң кулында – урманнар, куаклыклар. Әрәмәлек, инеш буе. Ә сулда – таулар рәте. Урта бер җирдә серле дә, шомлы да Кала-тау үзе калыккан...”* (18б) Шушы җөмләләр Кала-тауның серен белергә омтылу алдыннан кереш сүз булып тора. *“Кала-тауның йөрәге тибә иде. Кешенең йөрәк тибешенә охшамаган иде бу саңгырау тавыш...”* (28б.) Ә әсәрнең ахырына таба без Кала-тауның серлелеген үзебез тоя алабыз (*“Сәүбән белә: һәр елны җәй уртасында Кала-тау бер “тавышланып” ала. Бу вакытта аңа керергә, хәтта якын да барырга кушмыйлар. Бәла, афәт китерә торган көн бу. Тәңре туган, Алла туган көн. Изге рухларның явыз рухларга – җен-шайтаннарга каршы аяусыз көрәш башлаган көне. Кара рухлар җиңелеп, дөньга Тәңренең килгән сәгате.”* (127б.) *“Әмма Кала-тау шаукымы, аның белән бергә ниндидер чит-ят язмыш шаукымы көчлерәк, ахры. Аннан котылырга вакыт кирәк. Бәлки, бер мизгел, бер сәгать яисә бер көн, хәтта бер гомер кирәктер?”* (148б.)

Нәрсә соң ул – Кала-тау? Әсәрдә ул реаль һәм ирреаль дөньяларның чиге. Хыял дөньясына алып баручы символ итеп билгеләнә. Бала чагында Сәүбән хыял дөньясына якынрак булырга тырышты. Тау эчендә бары тик үзе генә белгән бүлмәсе бар иде аның. *“Бу бүлмәдә ул бала чагының иң моңсу, шулай ук иң бәхетле мизгелләрен кичерде. Күңеле үпкә-зардан, рәнҗештән әрнегән вакытта, шушында килеп, үзенчә юанып, олыларча сагышланып-уйланып, сәкесенә чалкан төшеп ята иде ул.”* (28б.) Сәүбәннең, аның

этисенең һәм баласының (Сәүбәннең) тормышлары шушы Кала-тау белән бәйле. Сәүбәннең малае инде сигез яшеннән шунда килә башлады һәм *“гомерлеккә шунда торып калды”*. Хәтта шушы Кала-тау эчендәге мәгарәдә яткан чакта вакыт узганын да тоймый иде ул, аның ниндидер серле көчкә ия булу турында ап-ачык белә иде *(“Шул таш өстенә биш кенә минут ятасың, ә чынында бер көн үтеп киткән була... Вакытны кыскарта, “йота” торган могҗизалы таш бу (...) Монда бер вакытта да ашыйсы, эчәсе килми. Күпме генә торсаң да, тамагың тук кебек, шулай ук хәлсезлек тә тоймыйсың монда; авырткан урыннар да тиз төзәлә...”* (127б.) Улын мәгарәдән эзләгәндә дә *“Сәүбән күпме йөгергәнен дә белми. Әллә ул бер сәгать йөгерә, әллә ике сәгать... Вакытның чамасы югалды. Хәле дә соңгы тамчысына кадәр чыгып бетте.”* (132б.)

Хатыны белән өйләнешкәч, Сәүбәнгә *өч ел* вакыт бирелде. Ходай, бәлки, Сәүбән акылга килеп кире авылга кайтыр, дигән, ахры. Өйләнешеп бергә тора башлагач ук, Сәүбән үзенең бәхетсез икәнен аңлаган иде. Шушы өч ел дәвамында ул аерылышу нияте белән яшәде, әмма Сәвия балага узгач, Сәүбәннең өмете сүнде *(“...Аларның уртак бәгырь җимеше туачак! Бер-берсен яратмаган ике җанны мәңгелеккә бәйләп куячак! Әле аерылышырга, яңа тормыш корырга, бәхетле булырга ниндидер өмет бар иде. Хәзер ул өмет тә бетте, сүнде...”* (29б.)

“Оча торган кешеләр” әсәрендә *җыр* кешенең җанлы булуын аңлата. Әгәр дә кеше җырлый икән – ул яши, аның тормышы дәвам итә. Җыр кеше җанының тере булуын күрсәтә *(“Җыр ул – җан тавышы, җан авазы бит...”* (45б.). Рәмзия җырлаган җырларны автор өмет җырлары дип атый, ә өмет – ул рухи хәләт, киләчәктә ниндидер яхшылыкны көтү. Сәүбән төш күреп яткан вакытта Рәмзия аның җаны өчен куркып, рухын тәненә кире кайтару нияте белән җырлый.

Сәвиянең җыры да яшәүнең, киләчәккә өметнең булуын билгели. *“Сәвия үз күңелендә тибрәлеп торган әлеге җырның каян килгәнен*

*хәтерләми... Бу мөһим дә түгелдер. Иң мөһиме – ул җыр бар. Димәк, күңеле буш түгел, аның рухы, җаны фани дөнья белән матур бәйләнештә яши... Җыр бит ул – чынбарлык белән күңел дөньясын тоташтырып торган сихри басма, күпер... Кеше, җырга, моңга тартылган саен, үз кадерен ныграк белә бара. Кешенең кадере булмаса, иң матур хыяллар да бернигә тормый.”* (142б.)

Әсәрдән күргәнебезчә, кояш, ай, йолдызлар вакыт белән тыгыз бәйләнештә, әмма ул гына түгел, алар геройларның хисләренә тәэсир итәләр *(“Кояш барыбер яктырта, Ай моңсуландыра, йолдызлар – өмет, хыял, ә Чулпан... яшәү мәгънәсе бирә... Авыл белән дә шулай. Андагы Кояш та, Ай да, йолдызлар да, алар арасындагы Чулпан да һаман бар, һаман яши, аларның барысы да вакыт юлында мәңгелек сәфәрдә...”* (113б.) Гомумән, элек-электән кешеләр вакытны кояш, ай ярдәмендә саныйлар иде, ә әсәрдә алар күбрәк мифик вазыйфаны башкаралар.

**Төп нәтиҗәләр:**

Без тикшергән әсәрләрнең икесе дә Г.Гыйльманов тарафыннан мифологизмга нигезләнеп иҗат ителгән. Романнарда вакыт төшенчәсенә караган сүзләр бик актив кулланыла. Әмма “Албастылар” әсәрендә бу сүзләр ачык мәгънә биргән булсалар, “Оча торган кешеләр” әсәрендә исә вакытны белдергән сүзләр бераз тоныграк төсмер алалар. Мәсәлән, “Албастылар” романында вакытны белдергән сүзләр *көн, төн, яз, кыш, җәй, көз* һ.б., күргәнебезчә, вакытны бик актив сурәтлиләр: *Көн-төн* – тәүлек вакыты, *яз-җәй-кыш-көз* – ел фасыллары. Әмма аларның һәрберсенең үзенә күрә аерым бер мәгънәсе бар. Ә “Оча торган кешеләр” әсәрендә кулланылган сүзләрнең кайберсен тескттан тыш кулланган булсак, аларның вакытка кагылышы булмас иде. Без аларның вакыт төшенчәсе белән бәйләнештә булуын контекстка нигезләнеп кенә ачыклый алабыз (*Кала-тау, җыр*). “Оча торган кешеләр” романында вакытны ачык сурәтләгән һәм еш очрый торган мондый сүзләр бар: *мәңгелек, гомер, унсигез ел, бала чак һ.б.*

## 2.2. Вакыт төшенчәсен белдергән морфологик чаралар

### 2.2.1. “Албастылар” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән морфологик чаралар

Сәнгати текстта вакытның телнең грамматик чаралары ярдәмендә белдерелүе дә әһәмияткә ия. Гадәттә, фигыльнең төрле заман формаларына нигезләнгән вакыт бирелеше әсәрнең вакыйгалар агышын билгеләргә дә, булган хәлләрнең эзлеклелеген ачыкларга да мөмкинлек бирә.

“Албастылар” әсәрендә исә хикәяләү өченче зат исеменнән алып барыла. Бу рәвешле эш итү авторга бернинди чикләүсез укучыны персонажның эчке дөньясына алып керергә һәм аны җентекләп, тирәнтен күрсәтергә, эчке хәрәкәтне күзәтергә, персонажларның кичерешләре, тәэсирләре, уйлары арасындагы сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен аңлатырга ярдәм итә. Хикәяләүче сөйләме фигыльләрнең төрле заманнарын иркен кулланырга мөмкинлек бирә. Ул, нигездә, хәзерге заман хикәя фигыль формаларын яратып куллана. Мәгълүм булганча, сөйләү моменты белән тәңгәл килгән эш – хәзерге заман була[41]. “Албастылар” әсәрендә хәзерге заман темпоральлегенең вакыт ягыннан киңәюе дә күзәтелә. Нәтиҗәдә, мондый фигыльләр темпораль вакытның чиксезлеген, вакыйгаларның салмак агышын җиткерү чарасына әвереләләр. Хәзерге замандагы фигыльләрнең кабатлануы моны тагын да көчәйтеп килә. Мәсәлән:

*“Олы юл. Урман аланнарына керә-керә бормаланып сузылган бу таш юл, очы-кырые булмаган мари урманнарын урталай кисеп, алга йөгерә дә йөгерә.”* (5 б.)

*“Урман юлыннан берәү бара. Дөресрәге, икәү баралар.”* (190 б.)

---

41 Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. Югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек. / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2001. – Б. 219.

Хәзерге заман хикәя фигыль формаларының муллыгы әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны вакыт ягыннан гомумиләштерә, без аны бүген булган яки хәзерге көндә дә булырга мөмкин хәлләр итеп кабул итәбез, геройлар белән бер язмыш кичерәбез. Гомумән, Хәлим-Нәфисәләр, Майялар – барысы да безнең арада яши кебек:

*“Әнә алар – минем геройларым – матур гәпләшә-гәпләшә чәй эчеп утыралар. Гүя берни дә булмаган. Гүя гомер буе алар шулай тату, дус һәм яратышып яшәгәннәр... Яшәүнең бөтен сере дә шундадыр шул: бәхетле була белүдә...”* (383 б.)

Автор үзенең образларын бүгенгедә сурәтли, ул аларны тере итеп күз алдына китереп бастыра. Сәнгати текстның көче дә шунда. Шул рәвешле, вакытның темпораль яктан хәзерге белән бәйләнеше сәнгатьчә хикәяләүне тәэсирлерәк итә.

Үткәннәр турындагы уйланулар үткән заман темпоральлеге белән тәгъбир ителә:

*“Хәлим бу кышта ике тормыш белән яшәде. Беренчесе аның өйдә иде – газиз әнисе янында, якын күршеләре, таныш-белешләре янында. Икенчесе хәтер урамнарында барды – үткән кыштагы урман вакыйгалары, гомумән, урман тормышы аңа бер минутка да тынгылык бирмәде.”* (92 б.)

*“Юк, таба алмады Хәлим утарны. Югарыга күтәрелгән кояш та, эзләгәнен тапмасмы, дип, кадакланган кебек, бер урында озаклап торып карады. Аннары, өметен өзеп, тагын аска – кичке офыкка тәгәрәде...”* (378 б.)

Сәнгати вакытның бер компоненты булган киләчәкне сурәтләүдә фигыльнең шул ук заманы ярдәмгә килә. Автор киләчәкне өмет тулы тасвирлый һәм аның, һичшиксез, матур булачагына ышына:

*“Кешене олы афәттән шушы Кояш, чишмә, кошлар, чәчәкләр, күбәләкләр коткарып калачак.” (190 б.)*

*“Белеп торам: ярдәм итәргә тели ул аларга. Урман юлы озын, барыбер бер куып җитәр аларны, яктылыкка өметкә, тормышка чыгарга булышыр.*

*Амин, шулай булсын!”* (191 б.)

Әлеге юллардан күренгәнчә, язучы киләчәкнең гүзәл булачагына ышанырга тели. Һичшиксез, аның геройлары бәхетле булырга тиеш. Укучының да теләкләре шулай яңгырый. Киләчәк заман темпоральлегенең билгеле һәм билгесез формасы да бу мисалларда һичшиксез үтәләчәк эшләрне белдерә.

Шул ук вакытта киләчәкнең билгесезлеге дә фигыль формалары белән тәгъбир ителә:

*“Шуңа күрә мин китәм. Язмышыбызга каршы китәм. Юл – мәрхәмәтле дөнья. Берәр вакыт очына чыгармын, җаныма тынычлык табармын әле. Ә хәзер минем бөтен дөньям утта... Тимә миңа, яме... Тагын шул. Әнкәйләргә әйт. Моңа кадәр югалмадым. Бу юлы да югалмам. Көтсеннәр, юлым төшсә, кем белә, кайтып та килермен әле...”* (291 б.)

Шул рәвешле, фигыльнең үткән – хәзерге – киләчәк заман формалары “Албастылар” романындагы сәнгати вакытны катлауландыралар, аны структур яктан оештыруда катнашалар. Хикәяләүнең өч вакыт күчәрен дә үз эченә алуы вакыйгаларның серлелеген, катлаулылыгын тәэмин итә.

## 2.2.2. “Оча торган кешеләр” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдергән морфологик чаралар

Горизонталь яссылыкта үз әсәрләрендә Г.Гыйльманов Вакыт категориясе белән бәйле үткән һәм бүген полюсларын аера. Геройларның үткәннәре рухи ярлылыкта, үз-үзен эзләп үткән булса бүгенгедә инде алар җан белән бәйле экзистенциаль кичерешләргә бирелеп яшиләр.[42]

Автор “Оча торган кешеләр...”дә Кешене төрле вакыт аралыгында мөстәкыйль яшәүче образ итеп карый. Моннан үткән-бүгенге-киләчәк кебек Вакытның төп категорияләре хронологик тәртиптә итеп түгел, ә бәлки бер-берсенә параллель агучы- яшәүче күренешләр итеп кабул ителә.[43]

Г.Гыйльмановның «Оча торган кешеләр» әсәренең үзәгенә фәлсәфи як (яшәү фәлсәфәсеме ул, дөньяны танып-белү яки кабул итү рәвешеме), рухи кыйммәтләр һәм татар халкының ислам, мәҗүсилек белән бәйле образлары, фикерләре куелган, алар аша экзистенциаль идеяләр үткәрелгән. Әлеге әсәр гел реалистик буяулар белән генә сугарылган татар әдәбиятында яңа юнәлеш - «метафизик реализм» юнәлешен формалаштырды. Метафизик реализм - Яшәешнең метафизик дәрәҗәсен ачуны үзмаксат итеп куйган, рухи эзләнүләрне нигез итеп алып, кеше күңеленең яшерен урыннарын, дөнья яратылышының серле, билгесез якларын үзенчәлекле итеп сурәтләгән алым. Әлеге алымның нигезе булып реализм кала һәм аңа «яшерен дөнья», «яшерен чынбарлык», «хакыйкый чынбарлык» дигән параллельләр өстәлә. [44]

Әсәр төп геройның унсигез елдан соң авылга әйләнеп кайтуаннан башлана. Күп тә үтми автор Сәүбәннең мәхәббәт хәтирәләрен яктырта. Вакыт дәвалый диләр, әмма җан яраларын гына түгел. Сәүбән Казанга китеп үз тормышын җайлый башлады, әмма “*Сәвияне тиз генә оныта алмады ул.*

---

[42] Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр. Галимҗан Гыйльманов иҗатына штрихлар / Алсу Шәмсутова. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. - 69б.

[43] Шунда ук. - 68б.

4. [44] http://jazucilar.narod.ru/gilmanov2.htm

*Дөресрәге, бер тамчы да оныта алмады. Кызык та, кызганыч та: бик озак эзләп, Сәвия исемле кызга өйләнде.”* (12б.) Сәүбәннең бала чагы да бернәрсә дә Сәүбәннең хәтереннән юкка чыкмаганын дәлилли: “*Дөресме шул: йөрәгеңдә җәрәхәтне вакыт тузаны да, тормыш юшкыны да каплап, томалап куя алмады бит...”* (30б.)

Билгеле булганча, кешеләр өч төрле вакыт мизгелендә яшиләр: үткән, бүгенге һәм киләчәк заман. Шуларның иң җаваплысы һәм мәшәкатьлесе – бүгенгесе, мавыктырып, үзенә тартучысы – киләчәк, ә иң бае – үткән заман. Кеше шул үткән заман хәзинәсеннән, ягъни тарихтан никадәр күбрәк байлык алса, бүгенгесе тагын да баерак, ә киләчәге бүгенгедән дә матуррак булачак.

Әсәрдә үткән һәм бүгенге көн чагыштырылып бара кебек: “*Элегрәк армиягә алынган егетләр, шушы эскәмиягә тезелешеп утырып, соңгы мәртәбә тәмәке көйрәтәләр.”* (14б.) Сәүбән һәм аның рухы беренче тапкыр очрашканда, рухы эскәмиядә утырып тора иде, *“Сәүбән дә малай чагында шушы эскәмиядә утырырга ярата иде.”* (14б)

Әсәр дәвамында Сәүбәннең бала чагы һәм олыгайган чагы янәшә баралар. Монда без хәзерге һәм үткән заман параллельлеген күрәбез. Бала чагы Сәүбәнгә “акыл кертү” өчен җибәрелә. Аны рухы үзе дә болай ди: *“...Син сукыр идең ул вакытта. Күңелең сукыр иде. Син хәзер дә сукыр. Мин синең күзләреңне ачарга, җаныңны сафларга килдем.”* (16б). Шушы нигездә Сәүбәннең бала чагы Сәүбәндә вөжданын уяту максаты белән мондый сүзләр әйтә: *“...Беләсең килсә, син минем кебек чакта әдәплерәк, акыллырак идең. Хәзер әллә нишләгәнсең... Дөньяга ачуың чыккан... Җиреңнән, суыңнан, чишмәңнән аерылып, бик озак яшәдең шул син.”* (25б.) Күргәнебезчә, монда хәзерге һәм үткән вакыт көрәше бара. Соңрак Сәүбән дә бала чагының *“йөз яшьлек картлар акылы”* булуына төшенде (*...ничә еллар буе каткан күңелемне эретте, җанымны иркәләде...Аннары... Аннары ул миңа элеккеге саф, самими, изге мәхәббәт хисләрен кайтарды, мине бәхеткә ымсындырды, киләчәккә өметләндерде, яшәүгә үсендерде...”* (51б.).

*“...Бу гамьле кешенең исеме – Сәүбән. Ул ерак каладан туган авылына кайтып бара. Унсигез ел кайтмаган ул туган нигезенә. Менә хәзер кайтып бара. Ялгызы гына кайта. Юк-юк, әллә ниләр уйламагыз. Гаиләсе бар аның: хатыны, үсеп җиткән малае бар. Бу хакта бер сөйләр әле ул сезгә. Ә хәзер аның вакыты юк. Ул борчылып уйлана. Шулай борчылып, тәүлек буе поездда кайтты, менә хәзер дә – авыл юлына төшкәч тә – күңелен җыеп ала алмый, уйлана да уйлана, сызлана да сызлана...”* (7б.) Сәүбәннең борчылуы поездан төшү белән генә башланмады шул... Ул аның авылга кайтмаган унсигез ел гомере буе җанын битәрләде. Гаиләсе булса да, йорт учагы кабызылган булса да, җылыта иде микән ул? Киләчәк бәхетле булсын өчен, бүгенге көнне бәхетле итәргә кирәк. Артка карама диләр, ә бүгенге көн җанны битәрләп башланса мәсьәләнең чишелешен кайда эзләргә? Үткәндә түгел мени?

Уткән гомер кайтмый диләр, әмма автор Сәүбәннең бала чагы аша капма-каршы фикер әйтә: *“...Кеше, бала чагым үтте дә онытылды, хәтер чоңгылларына матур һәм гыйбрәтле истәлек булып төшеп, югалып калды, дип уйлый. Һәм ялгыша!.. Аның бала чагы гел янында, гел янәшә йөри... Ничек күрсен ул аны! Тормыш ваклыкларыннан аның күңеле сөрсегән, җаны изаланган, йөрәге җәрәхәтләнгән, бәгыре* каткан *була. Күзендәге яшәү нуры, өмет нуры тоныкланган, йөз суы кипкән була...”* (28б.) Бала чак елларыннан үтү өчен, кешегә берничә минут вакыт кирәк, Г.Гыйльманов да шул фикер яклы: *“...Шушы берничә минутта аның уй йомгагы балалык елларын урап кайтыргы өлгергән иде...”* (35б.)

Романның төп герое Сәүбән үткән гомерен кызганса да, ул якты киләчәк килүенә өмет итә *(“Сәүбән бу көннәрдә ачык тоеп, аңлап яшәде: бөтен нәрсәне югалткан очракта да бер нәрсә һәрвакыт кала – киләчәк. Киләчәк өметтән дә өстенрәк. Ул хыял белән янәшә.”* (115б.)

Хәзерге һәм үткән заман фигыль формасы ярдәмендә үзебезне сурәтләнгән вакыйгаларның катнашучылары булып хис итәбез. Кала-тауның сихри дөньясына, аның тарихына телепортация аша узабыз кебек. Чулпан

йолдызыннан төшкән рухлар белән элемтәгә керәбез сыман, үзебезне аларның сихри дөньясының өлеше итеп тоябыз.

Хәзерге заман формасында Хөсни карт тарафыннан сөйләнгән риваятьләр тарих яки миф булып калса да, без аларны ачык итеп күзалдыбызга китерә алабыз: *“Галәмнән төшкән кешеләр ә-ә-әнә теге әрәмәлек буйларында шәһәр төзи башлыйлар. Әмма җир кешеләренең явызлыгын белмиләр әле алар. Төзеп кенә бетерәләр, җирдәге кыргый затлар бу шәһәргә һөҗүм итәләр, аны яндырып, пыр туздырып китәләр. Шулай берничә мәртәбә кабатлангач, Зөһрә-ана оныклары шәһәрләрен тау эченә салырга булалар...”* (22б.)

Нәрсәне дә булса тасвирлауда киләчәк заманның билгеле һәм билгесез формалары ярдәм итә. Киләчәк заманның билгеле формасын кулланганда, автор безгә теге яки бу вакыйганың булачагына ышандырырга тели: *“Әмма шуны аерымачык белә иде: мәһабәт ерткыч җанвар авызы кебек ыржаеп ачылып торган бу тау куышы тиздән аның үзен генә түгел, аңа газиз булган бүтән җаннарны да кабып йотачак, аларны яңадан-яңа сынауларга дучар итәчәк.”* (93б.) Сәүбәннең бала чагы Сәүбәннең Сәвия һәм баласы алдында бурычы булуын әйтә: *“Сиңа хәзер авылдагы улың өчен дә яшәргә туры киләчәк! Менә бу бәхетсез хатынның язмыш юлы синеке белән янәшә барачак хәзер...”* (112б.)

**Төп нәтиҗәләр:**

“Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” әсәрләрендә автор үткән-хәзерге-киләчәк заман формалары ярдәмендә безгә вакытны катлауландырып тәкъдим итә. “Албастылар” әсәре бөҗралы темпоральлеккә нигезләнгән булса, “Оча торган кешеләр” әсәрендә үткән, хәзерге һәм бүгенгесе параллель рәвештә баралар. Әсәрләрдә заманның һәр формасы бер-берсенә нигезләнеп, бер-берсеннән аерылгысыз яши, Сәүбәннең тормышына мәгънә кертеп тора (Сәүбәннең балачагы – үткәне, Сәүбән үзе – хәзерге, Сәүбән (Сәүбәннең улы) – киләчәге).

## 2.3. Вакыт төшенчәсен белдерүгә ярдәм иткән график чаралар

### 2.3.1. “Албастылар” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдерүгә ярдәм иткән график чаралар

Теләсә нинди сәнгати текст композицион яктан төгәлләнгән, бербөтенгә тупланган тел чаралары җыелмасыннан тора. Анда һәр сүзнең, һәр тамганың, һәр билгенең үз урыны, тирән мәгънәви эчтәлеге бар. Әгәр дә автор әсәр кысаларына теге яки бу образны, чараны, тамганы кертеп җибәрә икән, бу юкка түгел. Бигрәк тә постмодернизм рухында иҗат ителгән әсәрләрдә һәр сүз төбендә олы сер яшеренгән. Г.Гыйльманов кебек сүз сәнгатенең сихри-серле көчен укучыга җиткерә алган әдип иҗатында бу бигрәк тә ачык чагыла. Аның без тикшерү үзәгенә алган “Албастылар” романында сәнгати вакытның оештырылышы график чаралар ярдәмендә дә тормышка ашырыла. Язучы телнең пунктуацион мөмкинлекләреннән – тыныш билгеләреннән оста файдаланып, вакыт күчәренең катлаулы агышын тудыра. Романда без график чараларның тулы гаммасын очратабыз: биредә нокталар, ноктaлы өтерләр, өндәүләр дә һ.б. тыныш билгеләре дә мулдан урын алган. Бу – сәнгати вакытның үзенчәлекләре белән дә аңлатыла. Әсәрдә вакыт агышының салмак кына, үз көенә генә аккан урыннарында автор нокта белән тәмамланган хикәя җөмләләр белән эш итә. Мондый өзекләрдә

сурәтләнгән вакыйгалар вакыт ягыннан дәвамлы яки мизгелдә тукталып калган кебек тоела:

*“Хәлим күпме барганын белми. Акрын гына, мыштым гына бардылар да бардылар алар. Көн кичкә авышты. Урман өстендә күк яктылыгы чагылып калгаласа да, аста инде эңгер-меңгер хакимлек итә. Хәлим берничә мәртәбә абынып та егылды, алдыннан һәм артыннан баручы ике шәүлә исә, бер адым да читкә тайпылмыйча, үзләре генә белгән сукмак буйлап һаман баралар.”* (58 б.)

Әлеге мисалдагы җөмләләрнең *нокта* белән төгәлләнгән булуы вакыт агышын салмак, табигый итә. Шул ук вакытта тыныч интонациянең *күпме вакыт барганын белми, акрын гына, мыштым гына* кебек лексемалар белән бергәлектә бирелүе вакытны билгесез характерда итә.

Гомумән, нокта – вакытның гадәти агышын белдерә. Әмма “Албастылар” романында, гадәти вакыттан бигрәк, катлаулырак характердагы серле-томанлы, мифологик вакытның роле зур. Төп герой, урмандагы карчыклар, Майя-Нәфисә һ.б. белән бәйле сурәтләнгән мондый вакыт тора-тора үзенең гадәти агышын җуя, бөтенләй көтелмәгән борылышлар ала, тарих төпкелендәге хәтерне тартып чыгара, киләчәккә күз ташларга мөмкинлек бирә. Нәтиҗәдә, гадәти интонация күңелдә туган сораулар, риторик өндәүләр белән аралаша, шул нигездә, геройлар тормышындагы вакыйгаларның, аларның күңел кичерешләренең дә катлаулы характерда булуы җиткерелә. Түбәндәге мисалны карыйк:

*“Әмма урман белән бәйле уйлар тагын да газаплырак булып чыкты. Кая бара ул? Нигә бара? Ярый, кая барасын белсен дә ди. Ни көтә аны кара сихер оясында? Үзенең язмышы аянычлы булды. Ә менә Гөләшкә – газиз сабыена ни юрап бара? Аны афәткә юлыктырырга алып барамы? Бу күке тавышы, бәлки, зәхмәтле сихердер, ымдыр? Бәлки, нарасыйга сихер кагылып та өлгергәндер инде? Әнә бит ничек мәрткә киткән... Гомердә йокламаган йокысын йоклый... Гомердә күрмәгән төшләрен күрә...Елмайган була...*

*Әнисен күрәдер... Майяны... Их, Майя, Майя! Ник кешеләргә ышандың соң син?! Нигә аларны күңелеңә якын җибәрдең? Ник җаныңны өзеп бирдең? Ә алар... Җанга җан белән кайтарыр урында, җанга кан белән, таш белән кайтардылар... Их, Майя!”* (193 б.)

Биредә Хәлим уйлануларында киләчәк билгесезлеге (кая бару, нигә бару турындагы риторик сораулар), бүгенгенең гамьсез хәвефлелеге (*Гомердә йокламаган йокысын йоклый... Гомердә күрмәгән төшләрен күрә...*), үткәннең аянычлылыгы (*Их, Майя, Майя! Ник кешеләргә ышандың соң син?!*) тыныш билгеләренең куе палитрасы ярдәмендә җиткерелә, бер төенгә туплана.

“Албастылар” әсәрендә сәнгати вакыт мизгел – мәңгелек дихатомиясенә нигезле торгызыла. Мәңгелек кеше яшәешенең фани һәм бакый дөнья чикләрендә тирбәлүе, кылган гөнаһның буыннар аша күчә килүе, кеше гомеренең бетмәс юл образы белән уралып алуы белән бәйле фәлсәфи фикерләр аша торгызыла. Ул, нигездә, күпнокталар аша тәгъбир ителә:

*“Шулай да күк йөзендә Кояш бар. Урман куенында чишмә бар. Чишмә буендагы таллыкта кошлар сайрый. Талгын җилдә аланлыктагы кыңгырау чәчәкләре дулкынлана-дулкынлана үз биюләрен бии. Күбәләкләр оча...”* (190 б.)

Әлеге өзектә яшәешнең мәңгелеге хакындагы идея микротекстның күпнокталар белән тәмамлануы аша тагын да үтемлерәк итеп җиткерелә. Башта нокталар белән җөмләләрне тәмамлый, тәмамлый да автор, әйтерсең лә, соңгы җөмләдән соң нокта куярга теләми, укучыга фикерен дәвам итәргә, уйланырга урын калдыра.

Табигатьтәге кануннарның мәңгелеге турындагы идея дә күпнокталар аша тәгъбир ителә:

*“Өстә – кояш... Җылы, якты, игелекле күк... Аяк астында – дымсу, салкынча һәм чиркандыргыч сукмак... Бүре сукмагы... Кеше аяк баскан җир түгел бу. Ләкин урман Хәлимне тамчы да куркытмый. Иң явыз бүре дә*

*беренче булып кешегә ташланмый. Иң әшәке, төпсез сазлык та үзенең ризалыгын алмыйча кешене йотмый... Әйе, әйе, үз-үзеннән өмет өзгән адәм затына гына каныга табигать... Күңелендә ышаныч-өмете сүнмәгән кешене хөрмәт итә ул. Ярдәм итмәскә дә мөмкин. Әмма зыян да салмый...”* (193 б.)

Вакытның билгесез характерда булуына ишарә итүче тыныш билгеләре дә – күпнокталар:

*“Агач кәүсәсе авып төшкән мизгел эчендә бөтен гомерен кичереп өлгерде ул... Ап-ак җәймә өстендә яткан бала, атка атланып китеп баручы малай... Нәфисә... Ул туй күлмәгеннән. Нәрсә бу? Аның йөзен тирән җыерчыклар баскан... Менә ул тагын үзен күрә... Янында тагын кемдер бар... Кап-кара, озын чәчле, зәп-зәңгәр күзле кыз көлеп тора. Кем соң ул?..”* (56 б.)

Бу мисалдагы күпнокталар Хәлимнең саташулары белән бәйле вакытның билгесезлеген җиткерә. Алай гына да түгел, бирелә вакыт буталчык характердагы катлаулы берәмлек хасил итә.

*“Һи-и, Сабир абзый. Бер ел кайда яшәгәнен үзе дә белми бит ул... Бер еллык гомеренең бер бөртек мизгелен дә хәтерләми...”* (31 б.)

Бу җөмләләрдәге күпнокталар да *бер ел* төшенчәсе белән бәйле рәвештә герой күңелендәге билгесезлеккә ишарә итә.

Шулай, Галимҗан Гыйльманов тыныш билгеләрен сәнгати вакыт бирелешенә хезмәт иттерә. Төрле характердагы җөмләләр, гыйбарәләр аның әсәрен вакыт ягыннан үзенчәлекле итә.

### 2.3.2. “Оча торган кешеләр” әсәрендә вакыт төшенчәсен белдерүгә ярдәм иткән график чаралар

Г.Гыйльманов үзенең романнарында тыныш билгеләрен мул кулланып, аларга эмоциональ төсмер кертеп безгә тәкъдим итә. Без тикшерү максаты

итеп алган “Оча торган кешеләр” романында да сәнгати вакыт график чаралар ярдәмендә оештырыла. Язучы тыныш билгеләреннән иркен файдалана. Романда без график чараларның тулы рәтен күрә алабыз. Монда нокталар, өтерләр, күрнокталар, өндәүләр, сораулар һ.б. тыныш билгеләре кулланыла.

Текстның мәгънәсен ачыклауда тыныш билгеләренә аерата игътибарлы булу сорала. Дөрес яңгыраган тыныш билгесе әдипнең контесттан аңлашылган төп фикерен аныклый.[45]

Укучының игътибарын җәлеп итәрлек сорау, өндәү булмаганда, җөмлә ахырында нокта куела. Шулай ук нокта вакытның гадәти агышын күрсәтә: *“Имеш, бу Кала-тау – кеше кулы белән өелмәгән тау. Әйе-әйе, элек булмаган мондый тау. Тик аны җир кешеләре дә өймәгән. Күктән төшкән кешеләр күтәргән аны.”* (21б.) Биредәге нокталар гади хикәяләү билгеләре булып киләләр, әмма монда Кала-тауның килеп чыгышы, серле тарихы турында әйтелә.

Күпнокталар – вакытның билгесезлеген аңлатучы тыныш билгеләре:

*“Унсигез ел үткән дә киткән...*

*Ул арада дөнья ничек үзгәрде! Сарманай да, аның кешеләре дә үзгәргән булырга тиеш...”* (17б.)

*“Гомер – үткән көннәр түгел, гомер ул – истә калган көннәр... Сәүбән гомере – үткән көннәр генә, ахры...”* (20б.) Бу җөмләләрдә гомер турында уйлану кызгану хисе белән әйтелә. Шушы максаттан чыгып, күпнокталарның куелышына тагын мондый мисал китерергә була: *“Унсигез ел белән ике көн арасында аерма күбрәк шул... Ике йөрәге бар кебек аның. Әгәр бу дөрес булса, ике йөрәге булса, аларны ике Сәвиягә дә төгәл бүлеп бирер иде... Бер генә шул аның йөрәге... Гомере дә бер генә...”* (130б.)

---

45 Нуриев Г.С. Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге / Г.С. Нуриев. - Казан: Мәгариф, 2009. - 177б.

*“Белмәскә, шул синең бала чагың бит инде мин. Һаман ышанмаган буласың. Бигрәк сәер кеше син... Үз-үзеңне танымыйсың...”* (21б.)

Монда күп ноктала куелуы Сәүбәннең бала чагының үпкәләве булып, нидер тагын әйтергә теләве, әмма тыелып калуы турында әйтә.

Автор әсәрдә өмет белән бергә бәхетнең үлүе турында, якты киләчәкнең килмәве турында әйтә. Күпнокталар ярдәмендә ул шуны кызганып үз хисләрен безгә җикерә:

*“Әле аерылышырга, яңа тормыш корырга, бәхетле булырга ниндидер өмет бар иде. Хәзер ул өмет тә бетте, сүнде...”* (29б.)

*“Беләм дә соң... Их, белсәң иде син!.. Миңа шундый кыен хәзер... Минем хәзер нишләргә белми торган чак бит... Әткәй исән булса, иң беренче аңа барыр идем... Юк шул, ичмасам, ул да ташлап киткән...”* (66б.) Күргәнебезчә, монда Сәүбәннең югалып калган, нишләргә белми торган вакыты, шуңа да аның җаны өзгәләнә, тынычланыр урын тапмый.

Сәүбәннең туган җирсез үткән вакыты, унсигез елы мәңгелек, бер гомер белән чагыштырыла: *“...Унсигез ел буе туган җирсез яшәп кара әле... Бер елы, бер көне дә саргайта аның. Унсигез ел бит, бер буын алмашынган гомер... Бер гомер...”* (75б.) Унсигез елны мәңгелек булу безгә автор күпнокталар аша тәгъбир итә.

Сөйләмнең тойгылылыгы, рух күтәренкелеге яки ачыну өйдәү билгесе белән белдерелә. Сөйләмдә өндәү билгесенең мәгънәләре күптөрле. Аның ярдәмендә хис-кичерешләрне, дулкынлану мизгелләрен белдерергә мөмкин (*“Уен эшмени – унсигез ел бит!.. Авылдан чыгып киткәндә үсмер бала гына иде әле ул.”* (7б.)

Сорау билгесе белән тәмамланган җөмләләр эчтәлекләре буенча күптөрле. Кичекмәстән җавап таләп иткән җөмләләр була. Җавапсыз калырга тиеш, алдагы сүзгә күчеш өчен генә хезмәт иткән сораулар була. Сәүбән малаеның да сораулары бар, әмма ул аларга кем җавап бирергә тиеш икәнен белми. Ул сораулар әтисе белән беренче очрашканнан соң туа *(“Шул да*

*булдымы эткәй кеше? Ничә ел көткән эткәсе шулмы? Шушы кешегә космосны, йолдызларны ышанып тапшыралармы?”* (125б.) Авторның Сәүбән һәм Сәвия мәхәббәте кагылышлы сораулар туа: *“Сәвия белән Сәүбән мәхәббәтенең, бәхетенең гомере күпме соң? Әгәр алар бәхетле икән, бу бәхетнең гомере нинди?”* (142б.)

*“Кайда калган ул чаклар – бала чаклар – бал чаклар?!”* Алдагы җөмләдән күргәнебезчә сорау формасындагы раслаулы җөмләләр – риторик сораулар да очрый. Риторик сорауларда сорау һәм өйдәү билгесе куела.[46]

**Төп нәтиҗәләр:**

Г.Гыйльманов әсәрләренең икесендә дә график чаралары бер үк вазыйфа башкаралар. Укучыга тәэсир көчен арттыру максаты белән автор тыныш билгеләренең тулы гаммасын куллана. Әсәрләрдә нокта, өндәү, сорау билгеләре, күпнокталар актив булулары күзәтелә. Бу – сәнгати вакытның үзенчәлекләре белән дә аңлатыла. Аларның һәрберсе әсәргә эмоциональ төсмер кертә.

Гомумән, икенче бүлеккә нәтиҗә ясап әйтсәк, “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнары сәнгати вакытны бирүче лингвистик чараларның олы байлыгын үзләрендә туплаганнар. Сүзләр, грамматик формалар һәм график чаралар ярдәмендә төрледән-төрле борылышлар алган вакыт төшенчәсе әсәрдә мифологик карашлар белән баетыла, авторның укучыга мәңгелек яшәү кыйммәтләре хакындагы фикерен җиткерергә булыша.

---

[46] Нуриев Г.С. Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге / Г.С. Нуриев. - Казан: Мәгариф, 2009. - 181 б.

# ЙОМГАК

Татар әдәбиятының гасырлар чигендә башланган үсеше бүгенге көнгә кадәр кызу темплар белән дәвам итә. Милли сүз сәнгатебез чынбарлыкны сәнгатьчә сурәтләүнең яңадан-яңа, заманча алымнарын барлый, укучы өчен яңа, көтелмәгән булган темаларны күтәрә, образ-сурәт тудыруның үзгә формаларын эзли. Галимҗан Гыйльманов та, әлеге өлкәдә зур хезмәт куеп, укучысын серле-тылсымлы әсәрләре белән сөендереп тора. Аларда сәнгати вакыт бирелеше дә кызыклы һәм үзенчәлекле.

Гомумән, хәзерге вакытта әдәби текстны сәнгати яссылыкта өйрәнү актуальләшеп бара. Төрле галимнәрнең хезмәтләрендә текст эчке һәм тышкы форма бердәмлеге итеп карала һәм сәнгати текст та шушы яссылыкта анализлана.

Шуның бер аспекты буларак, сәнгати вакыт бирелеше дә әдәби әсәрне анализлауда әһәмиятле урын алып тора. чыннан да, әдәби вакыт һәм әдәби пространство (урын), хәзерге әдәбият белемендә махсус тикшерүне сорый торган проблема буларак, үз хокукын яулый. Текст эчендәге кисәкләр, берәмлекләр, берсе икенчесен алмаштырып килүче механик рәвештә өелгән баскычлар түгел, аларның диалектик яшәеше, эчке бәйләнешләре бик үзенчәлекле. Нәкъ менә шул бәйләнешне күз алдына китерү өчен, әдәби вакыт белән әдәби пространство мәсьәләсен анализлау кирәк тә. Хронотопны анализлау әдәби урын һәм вакытның түбәндәге төрләрен аеруны күздә тота: әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларның урыны һәм вакыты; тарихи

урын һәм вакыт, психологик урын һәм вакыт психологик процессларны һәм персонажларның субъектив хронотобын тергезү белән бәйләнгән.

Әдәби әсәрдә сәнгати вакытның бирелеше төрле чаралар белән тәгъбир ителә ала. Текстның һәр компоненты сөйләм сөрешендә вакыт төшенчәсенә теге яки бу дәрәҗдә ишарә итәргә мөмкин. Г.Гыйльмановның “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнарында сәнгати вакыт төшенчәсен белдергән лингвистик чараларны анализлау да аның әсәрләренең фәлсәфи тирәнлеген ачыкларга ярдәм итте.

Язучының бу романнарында вакытның лингвистик чаралар белән белдерелүе өч яссылыкта анализланды: вакыт төшенчәсенең төрле сүзләр белән бирелүе, вакытны грамматик формалар белән белдерү, вакытны график чаралар ярдәмендә тәгъбир итү.

Г.Гыйльмановның “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” романнары реаль һәм мифологик вакытларның үзара тыгыз бәйләнешенә корылганнар. Әсәрләрдә бирелгән аерым сүзләр, ачкыч гыйбарәләр дә шушы вакытларның катлаулы берлеген ачуга хезмәт итә. Автор лексик берәмлекләр аша кеше гомере, аның катлаулыгы, яшәешнең мәңгелек булуы хакында уйлана, мизгел – мәңгелек каршылыгын торгыза. Шулай ук көн – төн каршылыгы “Албастылар” романында яхшылык һәм явызлыкның мәңгелек көрәше хакында бәян итәргә мөмкинлек тудыра. Ел фасылларын төп геройлар тормышына мөнәсәбәтле торгызып, Г.Гыйльманов яшәү – үлем, яшәеш матурлыгы турында уйландыра. Әсәрдәге үлеп терелү мотивы исә кешенең гөнаһлы үткәннәреннән игелекле киләчәккә юл алуы булып аңлашыла. Шул ук вакытта романны үтәли узган юл образы мәңгелек турында уйландыра.

Без тикшергән әсәрләрнең икесе дә Г.Гыйльманов тарафыннан мифологизмга нигезләнеп иҗат ителгән. Романнарда вакыт төшенчәсенә караган сүзләр бик актив кулланыла. Әмма “Албастылар” әсәрендә бу сүзләр ачык мәгънә биргән булсалар, “Оча торган кешеләр” әсәрендә исә вакытны белдергән сүзләр бераз тоныграк төсмер алалар. Мәсәлән, “Албастылар”

романында вакытны белдергән сүзләр *көн, төн, яз, кыш, җәй, көз* һ.б., күргәнебезчә, вакытны бик актив сурәтлиләр: *Көн-төн* – тәүлек вакыты, *яз-җәй-кыш-көз* – ел фасыллары. Әмма аларның һәрберсенең үзенә күрә аерым бер мәгънәсе бар. Ә “Оча торган кешеләр” әсәрендә кулланылган сүзләрнең кайберсен тескттан тыш кулланган булсак, аларның вакытка кагылышы булмас иде. Без аларның вакыт төшенчәсе белән бәйләнештә булуын контекстка нигезләнеп кенә ачыклый алабыз (*Кала-тау, җыр*). “Оча торган кешеләр” романында вакытны ачык сурәтләгән һәм еш очрый торган мондый сүзләр бар: *мәңгелек, гомер, унсигез ел, балачак һ.б.*

Романнардагы грамматик чаралар да вакыт төшенчәсен тәгъбир итүдә катнаша. Хикәяләүче сөйләме фигыльләрнең төрле заманнарын иркен кулланырга мөмкинлек бирә. Ул, нигездә, хәзерге заман хикәя фигыль формаларын яратып куллана. Аларның вакыт ягыннан киңәюе дә күзәтелә. Нәтиҗәдә, алар вакытның чиксезлеген, вакыйгаларның салмак агышын җиткерү чарасына әвереләләр. Үткәндәге вакыйгалар үткән заман хикәя фигыль формалары белән белдерелсәләр, якты киләчәк турында уйланулар билгеле киләчәк заман формасында җиткерелә, ә алдагы көнгә өмет булмау киләчәк заманның билгесезлек варианты белән тәгъбир ителә. “Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” әсәрләрендә автор үткән-хәзерге-киләчәк заман формалары ярдәмендә безгә вакытны катлауландырып тәкъдим итә. “Албастылар” әсәре боҗралы темпоральлеккә нигезләнгән булса, “Оча торган кешеләр” әсәрендә үткән, хәзерге һәм бүгенгесе параллель рәвештә баралар. Әсәрләрдә заманның һәр формасы бер-берсенә нигезләнеп, бер-берсеннән аерылгысыз яши, Сәүбәннең тормышына мәгънә кертеп тора (Сәүбәннең балачагы – үткәне, Сәүбән үзе – хәзерге, Сәүбән (Сәүбәннең улы) – киләчәге).

“Албастылар” һәм “Оча торган кешеләр” әсәрләрендәге график чаралар да сәнгати вакытны оештыру ягыннан әһәмиятле. Г.Гыйльманов әсәрләренең икесендә дә график чаралары бер үк вазыйфа башкаралар. Укучыга тәэсир

көчен арттыру максаты белән автор тыныш билгеләренең тулы гаммасын куллана. Әсәрләрдә нокта, өндәү, сорау билгеләре, күпнокталар актив булулары күзәтелә. Бу – сәнгати вакытның үзенчәлекләре белән дә аңлатыла. Аларның һәрберсе әсәргә эмоциональ төсмер кертә. Әсәрләрдә вакыт агышының салмак кына, үз көенә генә аккан урыннарында автор нокта белән тәмамланган хикәя җөмләләр белән эш итә. Әмма вакытның каршылыклы, катлаулы берлеген җиткергәндә, гадәти интонация күңелдә туган сораулар, риторик өндәүләр белән аралаша. Мизгел – мәңгелек дихатомиясе исә күпнокталар аша тәгъбир ителә. Геройлар тормышындагы билгесезлек тә күпнокталарга мөрәҗәгать итеп җиткерелә.

Димәк, Г.Гыйльмановның “Албастлар” һәм “Оча торган кешеләр” романнары сәнгати вакыт бирелеше ягыннан шактый үзенчәлекле әсәрләр булып торалар. Аларны шушы аспекттан анализлау әле тагын да яңа юнәлешләр аша алып барыла ала.

## КУЛЛАНГАН ӘДӘБИЯТ


**Чыганак:**

1. Гыйльманов Г. Албастылар: Хыялый кыйсса / Г.Гыйльманов. – Казан: Тат.кит.нәшр., 2003. – 383 б.
2. Гыйльманов Г. Оча торган кешеләр: роман, повестьлар, бәяннар / Г.Гыйльманов. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. - 463б.

**Фәнни әдәбият:**

*Татар телендә:*

3. Г.Гыйльманов: “Тормыш кешене үзгәртә”... // Тәрәзә. – 2007. - №1-2. – Б. 12.
4. Дәүләтшина Л.Х. Киләчәккә күз төбәп... / Л.Х.Дәүләтшина // Казан утлары. – 2005. - №9. – Б. 154-158.
5. Җәләлиева М. Хыялый кыйссаны укыгач... / М.Җәләлиева // Мәгърифәт. – 2002. – 20 апр.
6. Заһидуллина Д.Ф. “Албастылар” яки татар прозасында яңа сыйфатлар / Д.Ф.Заһидуллина // Казан утлары. – 2001. - №11. – 111-119 б.
7. Заһидуллина Д.Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы / Д.Ф.Заһидуллина. – Яңадан эшләнгән һәм тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 367 б.
8. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих. / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 247 б.
9. Заһидуллина Д.Ф. Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачылык) / Заһидуллина Д.Ф. - Казан: Мәгариф, 2006. - 255б.

10.Фәнни язмалар.  Матур әдәбият телендә темпоральлекне белдерү чаралары/ Кузьмина Х.Х. - Казан, 2007. - 157-160 б.
11.Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленеңстилистик системасы / Х.Р.Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 187 б.
12.Поварисов С.Ш. Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү / С.Ш.Поварисов. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1978. – 152 б.
13.Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле / Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. – Казан: Мәгариф, 2006. – 245 б.
14.Сафиуллина Ф.С. Тел гыйлеменә кереш. Югары уку йортларының филология факультеты студентлары өчен дәреслек. / Ф.С.Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 2001. – 383 б.
15. Сәйфетдинова Л. Албастылар илендә / Л.Сәйфетдинова // Шәһри Казан. – 2004. – 26 март.
16.Татар грамматикасы: 3 томда. – М., Казан, Т.2: Морфология. – 2002. – 465 б.
17.Урманче Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда: 2т. (Д-С) / Фатих Урманче. - Казан: Мәгариф, 2009. - 343б.
18.Хаков В.Х. Татар әдәби теле (Стилистика) / В.Х.Хаков. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 243 б.
19.  Хафизов С. Тамырлары үзебездә / С.Хафизов // Казан утлары. – 2006. - №8. – 144-148 б.
20.Шәмсутова А.А. Хәзерге татар әдәбиятында яңарыш: фәнни мәкаләләр / Шәмсутова А. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. - 205б.

*Рус телендә:*

21. Бабенко Л.Г. Филологический анализ текста: основы теории, принципы и аспекты анализ / Л.Г.Бабенко. – М, Екатеринбург, 2004.

22.Бабенко Л. Г. Лингвистический анализ художественного произведения. Теория и практика / Л.Г.Бабенко, Ю.В.Казарин. – М.: Флинта, Наука. – 2004.
23.Бахтин М. М. Вопросы литературы и эстетики / М.М.Бахтин. – М., 1975.
24.Давлетшина Л.Х. Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI вв. / Л.Х.Дәүләтшина. – Казань: Школа, 2006. – 140 с.
25.Зобов Р.А., Мостепаненко А.М. О типологии пространственно-временных отношений в сфере искусства / Зобов Р.А., А.М.Мостепаненко // Ритм, пространство т время в литературе и искусстве. – М., 1974. – С. 14-22.
26. Ибрагимов М.И. Миф в татарской литературе XX века: проблемы поэтики / М.И.Ибрагимов. – Казань: Gumanitaria, 2003. – 64 с.
27.Литературная энциклопедия терминов и понятий / Под ред. Николюкина. Институт науч. Информации по общественным наукам РАН.— Москва: НПК “Интелвак”, 2003.
28.Нигматуллина Ю.Г. “Запоздалый модернизм” в татарской литературе и изобразительном искусстве / Ю.Г.Нигматуллина. – Казань: Фэн, 2002. – 176 с.
29.Николаева Т.М. Лингвистика текста. Современное состояние и перспективы / Т.М.Николаева //Новое в зарубежной лингвистике. Вып. 8. – М.: Прогресс, 1978. – С. 5-39.
30.Новиков А. И. Семантика текста и ее формализация / А.И.Новиков. – М.: Наука, 1983.
31.Новиков Л.А. Лингвистическое толкование художественного текста / Л.А.Новиков. – М., 1979.
32.Новиков Л.А. Художественный текст и его анализ / Л.А.Новиков. – М., 2007.

33. Нуриев Г.С. Сәнгатьле сөйләм: Уку ярдәмлеге / Г.С. Нуриев. - Казан: Мәгариф, 2009. - 199б.
34. Шанский А.М. Морфология современного русского языка / А.М.Шанский. – М.: Наука, 1970.
35. Эсалнек А.Я. Основы литературоведения. Анализ художественного произведения: Учеб. пособие / А.Я.Эсалнек. – Москва: “Флинта”: Наука, 2004.

**Кулланылган интернет сайтлары:**

1. http://adiplar.narod.ru/
2. http://jazucilar.narod.ru/gilmanov2.htm